# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 12), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Президентын сайлаулар турында

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның төп принциплары

1. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән биш елга сайлана. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар альтернатив нигездә башкарыла.

2. Татарстан Республикасы гражданы сайлауларда ирекле һәм ихтыярый катнаша. Татарстан Республикасы гражданын сайлауларда катнашырга яисә катнашмаска мәҗбүр итү максатында, шулай ук аның ирекле ихтыярый белдерүенә йогынты ясарга беркемнең дә хокукы юк.

261

2 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында законнар

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнардан гыйбарәт.

3 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда Татарстан Республикасы гражданнарының сайлау хокуклары

1. Сайлаулар көненә 18 яшькә җиткән Татарстан Республикасы гражданы Татарстан Республикасы Президентын сайларга хокуклы.
2. Татарстан Республикасы Президенты итеп Татарстан Республикасының утыз яшьтән дә яшьрәк булмаган, сайлау хокукына ия булган һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрен белүче гражданы сайланырга мөмкин.
3. Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган Татарстан Республикасы гражданнары, хөкем карары нигезендә иректән мәхрүм итү урыннарында тотылучы затлар Татарстан Республикасы Президентын сайларга һәм Татарстан Республикасы Президенты булып сайланырга хокуксыз.

4 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар, Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренең конституциячел чоры тәмамланырга өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Президенты сайланган конституциячел чорны исәпләү аны сайлаган көннән башлана.
2. Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында каралган нигезләрдә һәм тәртиптә, Татарстан Республикасы Президенты ризалыгы нигезендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар бүтән вакытка күчерелергә мөмкин, әмма ул өч айдан да артык булмаска тиеш.
3. Татарстан Республикасы Президенты үз вәкаләтләрен башкаруны конституциячел чор узганчы ук Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган очракларда һәм тәртиптә туктатса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны вакытыннан алда билгели. Бу очракта сайлаулар Татарстан Республикасы Президенты үз вәкаләтләрен башкаруны вакытыннан алда туктаткан көннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә. Мондый чакта әлеге Законда билгеләнгән сайлау гамәлләренең вакытлары дүрттән бергә кими.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләнгән вакытларга билгеләгән очракларда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан сайлаулар түбәндәгечә уздырыла:

Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре тәмамланганнан соң килүче айның беренче яисә икенче якшәмбесендә;

Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән соң 180 көннән дә соңга калмыйча.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турындагы (уздыру турындагы) карары аны кабул иткән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

<u>5 статья.</u> Сайлау округы һәм сайлау комиссияләре

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар Татарстан Республикасының бөтен территориясен үз эченә алган бердәм республика сайлау округы буенча уздырыла.

2. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны сайлау комиссияләре башкара.

3. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда сайлау комиссияләре дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан үз вәкаләтләре чикләрендә бәйсез булалар.

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар күрсәтү хокукы

1. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар (алга таба - кандидатлар) сайлау округы сайлаучылары тарафыннан һәм үз-үзләрен күрсәтү тәртибендә күрсәтелергә мөмкин. Кандидатлар сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары тарафыннан да күрсәтелергә мөмкин.

2. Кандидатларны күрсәтү хокукына ия булучы партияләрнең һәм республиканың башка сәяси җәмәгать берләшмәләренең исемлеге, сайлаулар көнен халыкка игълан иткәннән соң 7 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

<u>7 статья.</u> Сайлау алды үгетләве хокукы

1. Дәүләт Татарстан Республикасы гражданнарына һәм җәмәгать берләшмәләренә, сәяси партияләргә сайлау алды үгетләвен закон нигезендә ирекле уздыруны тәэмин итә.

263

2. Татарстан Республикасы гражданнары, җәмәгать берләшмәләре һәм сәяси партияләр Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашу өчен законда рөхсәт ителгән рәвешләрдә һәм закоилы ысуллар белән теләсә кайсы теркәлгән кандидатны хуплап яисә аңа каршы үгетләү алып барырга хокуклы.

3. Теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдалануның бертигез шартлары гарантияләнә.

8 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны финанслау

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле гамәлләрне финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

2. Кандидатлар үз сайлау кампаниясен финанслау өчен үз сайлау фондларын төзергә тиеш.

9 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм үткәргәндә хәбәрдарлык

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү ачык һәм хәбәрдар рәвештә гамәлгә ашырыла.

2. Сайлау комиссияләренең, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле һәм гражданнарның сайлау хокукларына кагылышлы карарлары бастырып чыгарылырга тиеш йә башка юллар белән гомуми игътибарга җиткерелә.

## II бүлек. Сайлау комиссияләре

10 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләре системасы

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне түбәндәгеләр башкара:

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе;

территория (район, шәһәр, шәһәрләрдәге район) сайлау комиссияләре;

участок сайлау комиссияләре.

11 статья. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе

1. Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасынын Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы сайлау комиссияләре эшчәнлегенә юнәлеш бирә.

2. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Законы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар белән билгеләнә.

12 статья. Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясен төзү тәртибе

1. Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясе, тавыш бирү көненә кимендә 70 көннән дә алдан һәм 60 көннән дә соңга калмыйча, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 10-18 әгъзасыннан сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының, җәмәгать берләшмәләренең, яшәү, эшләү, хезмәт итү һәм уку урыннары, буенча сайлаучылар җыелышларының тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Территория сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысы - халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары тарафыннан, икенче яртысы тиешле җирле администрация башлыгы тарафыннан билгеләп куела.

2. Халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы һәм җирле администрация башлыгы Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Дәүләт Думасында фракцияләре булган сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләре булган сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә үзләре билгеләп куючы территория сайлау комиссиясе әгъзаларының кимендә өчтән бер өлешен билгеләп куярга тиешләр.

3. Әгәр халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы һәм тиешле җирле администрация башлыгы территория сайлау комиссиясе составын йә аның бер өлешен билгеләнгән вакытка билгеләп куймаса яисә әлеге территориядә шушы орган булмаса, территория сайлау комиссиясе составын йә аның бер өлешен билгеләп кую Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

265

13 статья. Участок сайлау комиссиясен төзү тәртибе

1. Участок сайлау комиссияләре, сайлау участогы төзелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының, җәмәгать берләшмәләренең , яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыннары буенча сайлаучылар җыелышларының тәкъдимнәре нигезендә сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 6-12 әгъзасы составында халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы тарафыннан төзелә. Халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Дәүләт Думасында фракцияләре булган сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләре булган сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары тәкъдимнәре нигезендә участок сайлау комиссиясе составының кимендә өчтән берен билгеләп куярга тиеш. Бу чакта һәр сайлау берләшмәсеннән, һәр сайлау блогыннан бердән артык вәкил билгеләп куелмаска тиеш.

2. Әгәр халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы билгеләнгән вакытка участок сайлау комиссиясенең составын йә составының бер өлешен билгеләп куймаса йә әлеге территориядә шушы орган булмаса, участок сайлау комиссиясенең составын йә аның бер өлешен билгеләп кую тиешле территория сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

14 статья. Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясенең вәкаләтләре

1. Территория сайлау комиссиясе:

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны тиешле территориядә әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

һәр сайлау участогы буенча сайлаучыларның исемлекләрен төзи;

тиешле территориядә участок сайлау комиссияләренең эшчәнлеген җайга сала, әлеге сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата белдерелгән шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

участок сайлау комиссияләренең адресларын һәм телефон номерларын халыкка җиткерә;

сайлауларны әзерләү һәм үткәрү өчен бирелгән акчалар белән эш итә һәм аларны участок сайлау комиссияләренә бүлеп бирә, аларның максатчыл кулланылуын тикшереп тора;

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә, сайлау алды эшчәнлегендә тиешле территориядә кандидатларның барысы өчен дә бертигез хокукый шартлар үтәлешен тәэмин итә;

сайлау бюллетеньнәрен һәм башка төрле документларны участок сайлау комиссияләренә илтеп җиткерүне оештыра;

сайлаучыларга Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирә;

сайлау участокларында тавыш бирүне уздырганда участок сайлау комиссияләренә оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

тиешле территориядә Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда тавыш бирү йомгакларын билгели һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыра;

тиешле территориядә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча тавыш бирү йомгакларын массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә;

сайлауларны әзерләү һәм уздыру белән бәйле документларны саклауны һәм тапшыруны Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә;

кабат тавыш бирүне һәм кабат сайлауларны уздыруны тәэмин итә;

участок сайлау комиссияләрен биналар, транспорт һәм элемтә белән тәэмин итүне тикшереп тора һәм сайлауларны матди-техник тәэмин итүнең башка төрле мәсьәләләрен карый;

әлеге Закон нигезендә башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Әгәр Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе адресына әлеге сайлау комиссиясенең тавыш бирү һәм тавышларны санау тәртибен бозган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр һәм протестлар кермәгән булса һәм әлеге фактлар буенча судта тикшерү алып барылмаса, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 15 көннән соң һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны оештыру һәм уздыру өчен бирелгән акчаларның тотылышы турындагы хисапны Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе раслаганнан соң территория сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры туктатыла. Тавыш бирү йомгакларына карата шикаять яисә протест белдерелгән очракта, территория сайлау комиссиясенең вәкаләтләре Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан шикаятьнең, протестның асылы буенча катгый карар чыгарылганнан соң туктатыла.

<u>15 статья.</u> Участок сайлау комиссиясенең вәкаләтләре

1. Участок сайлау комиссиясе:

участок сайлау комиссиясенең урнашкан җире һәм эш вакыты турында, шулай ук тавыш бирү көне һәм урыны турында халыкка хәбәр итә;

сайлаучылар исемлекләре белән сайлаучыларны таныштыра, сайлаучылар исемлегендәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турында сайлаучылардан кергән гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы мәсьәләне хәл итә;

тавыш бирү өчен биналар, тавыш бирү әрҗәләре һәм башка җиһазлар әзерләүне тәэмин итә;

территория сайлау комиссиясеннән алынган белешмәләр нигезендә теркәлгән кандидатлар турында сайлаучыларга хәбәр итүне тәэмин итә;

сайлау участогы территориясендә сайлау алды үгетләвен алып бару тәртибенең үтәлешен тикшереп тора;

сайлау участогында тавыш бирүне оештыра;

тавышларны санауны үткәрә, сайлау участогында тавыш бирү йомгакларын билгели һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне тиешле территория сайлау комиссиясенә тапшыра һәм документларны архивка тапшыру өчен әзерли;

сайлау документларын саклауны һәм тиешле территория сайлау комиссиясенә тапшыруны тәэмин итә;

әлеге Законны бозу турындагы шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм алар буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

әлеге Закон нигезендә башка төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

2. Әгәр югарырак сайлау комиссиясе адресына әлеге сайлау комиссиясенең тавыш бирү һәм тавышларны санау тәртибен бозган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр һәм протестлар кермәгән булса һәм әлеге фактлар буенча судта тикшерү алып барылмаса, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 10 көннән соң участок сайлау комиссиясенең вәкаләтләре чоры туктатыла. Тавыш бирү йомгакларына карата шикаять яисә протест белдерелгән очракта, участок сайлау комиссиясенең вәкаләтләре югарырак комиссия яисә суд тарафыннан шикаятьнең, протестның асылы буенча катгый карар чыгарылганнан соң туктатыла.

<u>16 статья.</u> Сайлау комиссиясе әгъзасының статусы

1. Дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутатлары, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатлары, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайланулы урындагы затлары, судьялар, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатлар тәкъдим иткән сайлаучылар төркемнәренең, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары, сайлау комиссияләренең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары кандидатларның, теркәлгән кандидатларның ирләре йә хатыннары һәм якын туганнары яисә ккандидатларның, теркәлгән

кандидатларның турыдан-туры буйсынуындагы затлар сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары була алмыйлар.

2. Җитәкче белән буйсынучы арасындагы хезмәт мөнәсәбәтләре әлеге Законда турыдан-туры буйсынуны аңлата, мондый очракта беренчесе соңгысына карата хакими-боеру вәкаләтләренә ия була, ягъни буйсынучыны эшкә алу һәм аннан азат итү хокукына ия яисә эш урыны вәкаләтләре чикләрендә аңа үтәлүе мәҗбүри булган әмерләр, боерыклар һәм күрсәтмәләр бирергә, бүләкләү һәм дисциплинар җәза чаралары кулланырга хокуклы.

3. Дәүләт хезмәткәрләре булып эшләүче һәм шуның өстенә җирле үзидарә органнарында эш урыннарын биләүче затлар территория, участок сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының өчтән береннән артыграгын тәшкил итә алмыйлар.

4. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы бер үк вакытта бүтән сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы була алмый.

5. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлау комиссиясенең һәр утырышында катнашырга тиеш.

6. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы:

тиешле сайлау комиссиясе утырышлары хакында алдан хәбәр ала;

сайлау комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле сайлау комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирү уздыруны таләп итәргә хокуклы;

сайлау комиссиясе утырышындагы башка катнашучыларга көн тәртибе нигезендә сораулар бирергә һәм аларга төпле җаваплар алырга хокуклы;

тиешле һәм түбәнгерәк сайлау комиссияләренең теләсә кайсы документлары һәм материаллары (сайлаучылар исемлекләре, сайлау бюллетеньнәре), машинадан укыла торган саклагычлардагы документларны һәм материалларны да кертеп, һәм шушы документларның, материалларның (сайлаучылар исемлекләреннән, сайлау бюллетеньнәреннән тыш) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне таныклауны таләп итәргә хокуклы;

сайлау комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата тиешле югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка шикаять белдерергә хокуклы.

7. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан аны билгеләп куйган органның карары белән вәкаләтләр чоры тәмамланганчы ук түбәндәге очракларда азат ителергә мөмкин:

сайлау комиссиясе әгъзасының вәкаләтләрен туктатуы хакындагы язмача гаризасы булганда;

Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына күчеп киткәндә;

сайлау комиссиясе әгъзасына карата судның гаепләүче хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип, кайдалыгы билгесез яисә вафат булган дип танылганда;

сайлау комиссиясе әгъзасы Россия Федерациясе гражданлыгын югалтканда;

тиешле сайлау комиссиясе гаризасы, закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы даими рәвештә үз вазыйфаларын үтәмәүче дип танылганда;

сайлау комиссиясе әгъзасы вафат булганда;

әлеге статьяның 1 пунктында каралган бүтән төрле нигезләр булганда.

8. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының вәкаләтләре шулай ук сайлау комиссиясе таркатылган очракта да тәмамлана.

9. Сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләп куйган орган алда күрсәтелгән сәбәпләр аркасында киткән сайлау комиссиясе әгъзасы урынына, ул киткәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча, сайлау комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләп куярга тиеш.

10. Сайлау комиссиясенең сайлаулар әзерләү һәм уздыру чорына төп эшеннән азат ителгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының төп эш урыны буенча уртача хезмәт хакы саклана. Сайлау комиссиясенең сайлаулар әзерләү һәм уздыру чорында төп эшеннән азат ителгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына хезмәт өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасының республика бюджетыннан сайлаулар уздыруга бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә башкарылырга мөмкин. Территория һәм участок сайлау комиссияләренең сайлаулар әзерләү һәм уздыру чорына төп эшләреннән азат ителгән рәисенә һәм секретарена (территория сайлау комиссияләре өчен - тавыш бирү көненә кадәр 60 көн кала һәм участок сайлау комиссияләре өчен - тавыш бирү көненә кадәр 30 көн кала) ай саен Татарстан Республикасының республика бюджетыннан сайлаулар уздыруга бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән җиде минималь күләменнән артмаган күләмнәрдә түләү башкарыла.

11. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлаулар уздыру чорында администрация (эш бирүче) инициативасы белән эшеннән азат ителә алмый яисә үз ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый.

12. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы сайлаулар уздыру чорында Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына яки суд тәртибендә билгеләнүче административ җәза гамәлләренә тартыла алмый.

13. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кандидат теркәлгәннән соң, әлеге кандидат сайлау комиссияләренә сайлау комиссиясенә киңәш бирү тавышы хокукына ия берәр әгъза билгеләп куярга хокуклы.

14. Сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы, түбәндәгеләреннән гайре, комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының сайлауларны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләре хокукларына да тулаем ия була:

бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары, сайлау бюллетеньнәре бирергә;

сайлау бюллетеньнәрен сортларга аеруда һәм санауда катнашырга;

тавыш бирү йомгаклары һәм сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә төзүдә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларын кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга;

сайлау комиссиясе карарларына имза салырга.

<u>17 статья.</u> Сайлау комиссиясен тарату

1. Тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе гамәлгә яраксыз дип таныйрлык итеп территория, участок сайлау комиссиясе гражданнарның сайлау хокукларын бозган очракта, күрсәтелгән сайлау комиссиясе суд тарафыннан таратылырга мөмкин.

2. Территория, участок сайлау комиссиясен тарату турындагы гариза белән судка Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, шулай ук Татарстан Республикасы халык депутатларының гомуми санынннан кимендә өчтән бере составындагы Татарстан Республикасы халык депутатлары төркеме, йә халык депутатлары җирле Советларының халык депутатларының гомуми санынннан кимендә өчтән бере составындагы халык депутатлары җирле Советларының халык депутатлары төркеме, йә җирле үзидарәнең тиешле вәкиллекле органы депутатларының гомуми санынннан кимендә өчтән бере составындагы әлеге орган депутатлары төркеме мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Сайлау комиссиясен тарату турындагы гариза кичекмәстән карауга кабул ителә һәм аның буенча карар 14 көннән дә соңга калмыйча чыгарыла. Сайлау комиссиясен тарату турындагы эш суд тарафыннан коллегиаль рәвештә карала.

4. Вәкаләтләренә сайлау комиссиясен тарату кергән дәүләт хакимияте органнары сайлау комиссиясен тарату турындагы суд карары үз көченә кергәннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча тиешле сайлау комиссиясе төзергә тиеш.

5. Сайлау комиссиясен тарату тиешле сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләрен туктатуга китерми.

18 статья. Сайлау комиссияләре эшчәнлегендә хәбәрдарлык

1. Сайлау комиссияләренең эшчәнлеге ачык һәм хәбәрдар рәвештә башкарыла. Тиешле сайлау комиссиясенең утырышларында, шулай ук сайлаучылар исемлекләре, сайлау бюллетеньнәре, сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр белән тиешле участок, территория сайлау комиссиясе тарафыннан эш башкарылганда югарырак сайлау комиссиясе әгъзалары, теркәлгән кандидат яисә аның ышанычлы заты катнашырга хокуклы. Утырышларда катнашу өчен һәм күрсәтелгән сайлау документлары буенча эш башкарганда әлеге затларга өстәмә рөхсәт таләп ителми. Тиешле сайлау комиссиясе күрсәтелгән затларның утырышларга ирекле керә алуын һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эшләгәндә алардан ирекле файдалана алуын хәбәр итүне һәм шуларның мөмкинлеген тәэмин итә. Утырышларда һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эш башкарганда шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

2. Сайлау комиссияләренең карарлары матбугатта бастырыла һәм башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

3. Сайлау комиссияләре кандидатларны теркәү йомгаклары турындагы мәгълүматны, аларның биографик күрсәткечләрен, һәр теркәлгән кандидат буенча тавыш бирү йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен гражданнарга җиткерәләр.

4. Тавыш бирү көнендә участок сайлау комиссиясе эше башланган мизгелдән һәм югарырак сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең алынуы хакында хәбәр алынганга кадәр, шулай ук сайлаучыларның тавышларын кабат санаганда сайлау участокларында әлеге статьяның 1 пунктында санап үтелгән затлар, шулай ук күзәтүчеләр, чит ил (халыкара) күзәтүчеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләре үз эшчәнлекләрен законнар нигезендә гамәлгә ашыралар.

5. Теркәлгән кандидат, сайлау берләшмәсе, сайлау блогы, җәмәгать берләшмәсе үз мәнфәгатьләрен чагылдырган күзәтүченең вәкаләтләрен язма рәвештә таныкларга тиеш, һәм бу документта күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәгән җире, шулай ук ул җибәрелгән сайлау участогының номеры, сайлау комиссиясенең исеме күрсәтелә. Әлеге документ бары тик паспортын яисә аны алмаштырырлык документны күрсәткәндә генә дөрес була. Күзәтүче җибәрү турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

6. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы:

сайлаучылар исемлеге белән танышырга;

тавыш бирү көнендә тиешле сайлау участогында тавыш бирү бинасында булырга;

тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргәндә катнашырга;

сайлаучылар исемлекләренә кертелгән гражданнарны, сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәрен, тотылган сайлау бюллетеньнәрен санауны күзәтергә; тавыш бирү бюллетеньнәре үзләренә күренерлек ераклыкта һәм шартларда сайлау участогында сайлаучыларның тавышларын санауны күзәтергә; сайлаучыларның тавышларын санаганда теләсә кайсы тутырылган яисә тутырылмаган сайлау бюллетене белән танышырга; сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә һәм башка төрле документлар төзүен күзәтергә;

участок сайлау комиссиясенә тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белән мөрәҗәгать итәргә;

участок сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе белән, шулай ук башка төрле сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары һәм сайлауларның нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән танышырга; тиешле сайлау комиссиясеннән күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән документларның, шулай ук тиешле сайлау комиссияләренә кергән башка төрле документларның йә әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән чорда күрсәтелгән комиссияләр тарафыннан төзелгән документларның күчермәләрен, шул исәптән тавыш бирүдә катнашкан затларның исемлеген дә әзерләргә яисә соратып алырга. Күзәтүче таләбе буенча сайлау комиссиясе күрсәтелгән күчермәләрне бирергә яисә таныкларга тиеш;

тиешле комиссияләрдә сайлаучылар тавышларын кабат санаганда катнашырга;

участок сайлау комиссиясенең, башка төрле сайлау комиссиясенең гамәлләре (гамәл кылмаулары) хакында югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка мөрәҗәгать итәргә.

7. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

сайлаучыларга сайлау бюллетеньнәре бирергә;

сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетенен алган өчен аның урынына имза салырга;

сайлаучының үтенече буенча сайлау бюллетенен тутырырга;

тавыш бирү яшеренлеген бозарлык башка гамәлләр кылырга;

сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлау бюллетеньнәрен санаганда турыдан-туры катнашырга;

сайлаучылар арасында үгетләү эшләре алып барырга;

тиешле сайлау комиссиясе карар кабул иткәндә катнашырга;

сайлау комиссиясе эшенә комачаулык итәрлек гамәлләр кылырга.

8. Сайлау комиссиясе гамәлләренә катышу рөхсәт ителми. Күзәтүчеләрнең кисәтүләре һәм тәкъдимнәре сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан, ә кирәк чакта - сайлау комиссиясе утырышында карала.

9. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре участок сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре белән, шулай ук башка сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы яисә сайлауларның нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән танышырга йә тиешле сайлау комиссиясеннән күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән башка төрле документларның күчермәләрен әзерләргә һәм алырга хокуклы. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкиле таләбе буенча сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында яисә сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмәнең күчермәсен таныкларга тиеш.

10. Сайлау комиссияләре беркетмәләренең һәм башка төрле документларның күчермәләрен таныклау сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре тарафыннан башкарыла. Бу чакта таныкланучы документка күрсәтелгән затлар «күчермә дөрес» дип язалар, имза салалар һәм тиешле сайлау комиссиясенең мөһерен куялар.

<u>19 статья.</u> Сайлау комиссияләренең эшен оештыру

1. Сайлау комиссиясенең эшчәнлеге коллегиаль рәвештә гамәлгә ашырыла.

2. Сайлау комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре аның беренче утырышында яшерен тавыш бирү юлы белән сайлау комиссиясе әгъзалары арасыннан сайлана.

3. Әгәр сайлау комиссиясе утырышында сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелеге катнашса, ул утырыш вәкаләтле була.

4. Тиешле сайлау комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасының, шулай ук югарырак сайлау комиссиясенең утырышта катнашучы теләсә кайсы әгъзасының таләбе буенча сайлау комиссиясе үз компетенциясенә керүче һәм расланган көн тәртибе нигезендә утырышта сайлау комиссиясе тарафыннан каралучы теләсә кайсы мәсьәлә буенча тавыш бирүне уздырырга тиеш.

5. Сайлау комиссияләре карарларын кабул иткәндә хуплап бирелгән һәм каршы тавышлар тигез булган очракта, сайлау комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

6. Үз вәкаләтләре кысаларында сайлау комиссияләре кабул иткән карарларның үтәлеше дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук түбәнгерәк сайлау комиссияләре, дәүләт учреждениеләре, теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, урындагы затлар һәм сайлаучылар өчен мәҗбүри.

7. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кандидатларны теркәү һәм кандидатлар теркәүне юкка чыгару хакындагы, сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү мәсьәләләре турындагы, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү турындагы, сайлауларны узмаган яисә гамәлгә яраксыз дип тану турындагы, кабат тавыш бирү яисә кабат сайлаулар үткәрү турындагы, сайлау комиссиясе карарын юкка чыгару турындагы карарлары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

8. Башка сайлау комиссияләренең сайлау комиссиясе рәисен, рәис урынбасарын һәм комиссия секретарен сайлау турындагы, сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанс белән тәэмин итү мәсьәләләре хакындагы, тавыш бирү йомгакларын билгеләү, сайлау комиссиясе карарын юкка чыгару хакындагы карарлары шулай ук сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

9. Сайлау комиссияләренең башка төрле мәсьәләләр буенча карарлары сайлау комиссиясенең шунда катнашучы хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

10. Сайлау комиссиясе карарына сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала.

11. Сайлау комиссиясенең кабул ителгән карары белән килешмәгән сайлау комиссиясе әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язма рәвештә белдерергә хокуклы, шушы комиссия, өч көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн кала, тавыш бирү көнендә һәм тавыш биргәннән соңгы көндә кичекмәстән бу фикерне карарга һәм аны беркетмәдә чагылдырырга, беркетмәгә кушымта итеп бирергә һәм югарырак сайлау комиссиясенә җиткерергә тиеш.

12. Сайлау комиссиясенең законны бозып кабул ителгән карары югарырак сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш.

13. Сайлау комиссиясенең утырышлары сайлау комиссиясе рәисе яисә аның кушуы буенча рәис урынбасары тарафыннан чакырыла һәм уздырыла. Сайлау комиссиясе утырышлары шулай ук сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының кимендә өчтән бере таләбе буенча да уздырылалар.

14. Сайлау комиссияләренең утырышларында шикаятьләр (гаризалар) каралганда кызыксынучы якларның вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

20 статья. Сайлау комиссияләренең эшчәнлегенә ярдәм итү

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм дәүләт милке өлешенә ия оешмалар, шулай ук аларның урындагы затлары сайлау комиссияләренә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда, шул исәптән кирәкле биналар, транспорт, элемтә чаралары һәм техник җайланмалар бирүдә ярдәм итәргә, шулай ук белешмәләр һәм материаллар бирергә, сайлау комиссияләренең мөрәҗәгатьләренә - биш көн эчендә, ә сайлауларга биш көн кала һәм сайлаулар көнне кичекмәстән җавап бирергә тиешләр. Гамәлгә куючылары (гамәлгә куюда катнашучылары) дәүләт органнары яисә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары булган теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм көндәлек матбугат басмалары редакцияләре сайлау комиссияләренең басма мәгълүматын урнаштыру өчен мөмкинлек бирергә, шулай ук сайлаучыларга хәбәр итү өчен сайлау комиссияләренә түләүсез эфир вакыты бирергә тиешләр.

21 статья. Сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерү

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең һәм аның урындагы затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Татарстан Республикасы Югары судына шикаять белдерелергә мөмкин.

2. Башка сайлау комиссияләренең һәм аларның урындагы затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата югарырак сайлау комиссиясенә яисә район (шәһәр) судына шикаять белдерелергә мөмкин. Югарырак сайлау комиссиясенә алдан мәрәҗәгать итү судка мөрәҗәгать итүнең мәҗбүри шарты түгел.

3. Суд тарафыннан шикаятьләр һәм сайлау комиссиясенә шундыйрак шикаять белән килгән гражданның мөрәҗәгате карауга алынган очракта, сайлау комиссиясе, суд карары закон көченә кергәнче, шикаятьне карауны туктатып тора. Суд кергән шикаять турында сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

4. Судка кергән шикаятьләр (гаризалар) федераль законда билгеләнгән вакытларда федераль закон нигезендә суд тарафыннан карала.

5. Сайлау кампаниясе барышында кергән шикаятьләр буенча карарлар федераль закон нигезендә биш көн эчендә кабул ителә, әмма тавыш бирү көне алдыннан да соң түгел, ә тавыш бирү көнендә яисә тавыш бирүдән соң килүче көндә - кичекмәстән. Шикаятьләрдәге фактлар өстәмә тикшерүне таләп иткән очракта, алар буенча карарлар ун көннән дә соңга калмыйча кабул ителә. Тавыш бирү йомгаклары турында, сайлаулар нәтиҗәләре турында сайлау комиссиясе карарына шикаять буенча суд

шикаять бирелгән көннән ике айдан да соңга калмыйча федераль закон нигезендә карар кабул итәргә тиеш.

6. Югарырак сайлау комиссиясе, түбәнгерәк сайлау комиссиясенең карарыи юкка чыгарып, шикаятьнең (гаризаның) асылы буенча мөстәкыйль рәвештә карар кабул итәргә хокуклы.

7. Тиешле сайлау комиссияләре өчен суд карарларын үтәү мәҗбүри.

## III бүлек. Сайлау участокларын төзү. Сайлаучылар исемлекләре

<u>22 статья.</u> Сайлау участокларын төзү

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларында тавыш бирүне уздыру һәм тавышларны санау өчен сайлау участоклары төзелә.

2. Сайлау участоклары, җирле һәм башка шартларны исәпкә алып, сайлаучыларга мөмкин кадәр уңай шартлар тудыру йөзеннән, тиешле территория сайлау комиссиясе белән килештереп, тавыш бирү көненә кадәр кимендә 30 көн кала җирле хакимият башлыгы карары нигезендә төзелә.

3. Сайлау участоклары түбәндәге таләпләрне исәпкә алып төзелә:
һәр сайлау участогында 3000нән артык булмаган сайлаучы булу;
районнарның, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның гамәлдәге чикләрен бозмау.

4. Шифаханәләрдә, профилакторийларда, ял йортларында, сырхауханәләрдә, бүтән стационар дәвалау-профилактикалау учреждениеләрендә һәм сайлаучыларның башка вакытлыча тору урыннарында сайлау участоклары - әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән вакытта, ә аерым очракларда - тавыш бирү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

5. Номерлары, чикләре, адреслары һәм участок сайлау комиссияләренең телефон номерлары күрсәтелгән сайлау участокларының һәм тавыш бирү биналарының исемлекләре тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча җирле матбугатта җирле администрация башлыгы тарафыннан бастырып чыгарыла.

<u>23 статья.</u> Сайлаучылар исемлеге һәм аны төзү тәртибе

1. Сайлаучылар исемлеген билгеләнгән рәвештә җирле администрация тарафыннан бирелүче күрсәткечләр нигезендә, сайлаучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланып, территория сайлау комиссиясе төзи.

2. Сайлау участокларында сайлаучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә актив сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасы гражданнары кертелә.

3. Конкрет сайлау участогында гражданны сайлаучылар исемлегенә кертү өчен аның шушы сайлау участогы территориясендә даими яисә күбесенчә яшәү факты нигез була.

4. Сайлаучы бары тик бер генә сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин.

5. Хәрби частьтәге хәрби хезмәткәр-сайлаучыларның, аларның гаилә әгъзаларының һәм башка сайлаучыларның исемлеге, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр, хәрби часть командиры бирә торган күрсәткечләр нигезендә төзелә.

6. Хәрби частьтән читтә яшәүче хәрби хезмәткәрләр яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә гомуми нигезләрдә кертеләләр.

7. Тавыш бирү көнендә шифаханәләрдә, профилакторийларда, ял йортларында, сырхауханәләрдә, бүтән стационар дәвалау-профилактикалау учреждениеләрендә һәм башка вакытлыча тору урыннарында сайлаучылар исемлекләре шушы учреждениеләрнең җитәкчеләре бирә торган күрсәткечләр нигезендә аларның тору урыны буенча төзелә.

8. Көндез укып, тулай торакларда яшәүче студентлар һәм аспирантлар тулай торак урнашкан урындагы сайлаучылар исемлегенә кертеләләр.

9. Сайлаучылар исемлеге һәр сайлау участогы буенча аерым, алфавит тәртибендә яисә тавыш бирүне оештыру өчен бүтән уңайлы тәртиптә (торак пунктлары, урамнар, йортлар, сайлаучыларының адреслары буенча), Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвештә төзелә.

10. Сайлаучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Исемлектә сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (унсигез яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае) һәм даими яисә күбесенчә яшәү урынының адресы күрсәтелә. Сайлаучылар исемлегенә - территория сайлау рәисе һәм секретаре, ә күрсәтелгән исемлекне участок сайлау комиссиясенә тапшырганнан соң участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре да имза сала. Хәрби часть территориясендә төзелгән сайлау участокларында сайлаучылар исемлегенә участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Сайлаучылар исемлеге тиешле территория һәм участок сайлау комиссиясенең мөһере белән таныклана.

11. Тиешле территория сайлау комиссиясе участок сайлау комиссияләренә конкрет сайлау участогы сайлаучыларының исемлеген тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча акт буенча тапшыра.

12. Сайлаучылар исемлеген сайлаучыларны таныштыру өчен тапшырганнан соң сайлау участогы территориясенә килеп урнашкан сайлаучылар, шулай ук теге яисә бу сәбәпләр аркасында сайлаучыларның төп исемлегенә кертелми калган сайлаучылар паспорт яисә аны алмаштыручы документ, ә кирәк чакта - сайлаучыларның шушы сайлау участогы территориясендә даими яисә күбесенчә яшәү фактын раслаучы документлар нигезендә өстәмә рәвештә участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлаучылар исемлегенә кертеләләр.

13. Сайлаучылар исемлеге сайлаучыларны таныштыру һәм өстәмә төгәлләштерү өчен тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча участок сайлау комиссиясе тарафыннан бирелә.

14. Актив сайлау хокукына ия гражданга аны сайлаучылар исемлегенә кертмәү турында, шулай ук сайлаучылар исемлегендәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турында участок сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итү хокукы бирелә. Участок сайлау комиссиясе 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә - мөрәҗәгать иткәннән соң 2 сәгать эчендә, әмма тавыш бирү төгәлләнү мизгеленнән дә соңга калмыйча , гаризаны, шулай ук тапшырылган документларны тикшерергә тиеш һәм хатаны яисә төгәлсезлекне бетерергә йә мөрәҗәгать итүчегә, гаризаны кире кагу сәбәпләрен бәян итеп, язмача җавап бирергә тиеш. Сайлаучылар исемлегенә территория сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза салганнан соң гражданны сайлаучылар исемлегеннән төшереп калдыру бары тик сайлаучыларны теркәүне (исәпкә алуны) гамәлгә ашыручы тиешле органнардан алынган белешмәләр нигезендә генә башкарыла. Мондый чакта сайлаучылар исемлегендә гражданны исемлектән төшереп калдыру датасы һәм аның сәбәбе күрсәтелә. Әлеге язма участок сайлау комиссиясе рәисенең имзасы белән таныклана. Участок сайлау комиссиясенең карарына карата югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка шикаять белдерелергә мөмкин, алар шикаятьне (гаризаны) - өч көн эчендә, ә тавыш бирү көнендә кичекмәстән карарга тиеш. Мөрәҗәгать итүче файдасына хәл ителгәндә, сайлаучылар исемлегенә төзәтмә участок сайлау комиссиясе тарафыннан кичекмәстән кертелә.

15. Тавыш бирү төгәлләнгәннән соң һәм сайлаучылар тавышларын санау башлангач, сайлаучылар исемлегенә үзгәрешләр кертү тыела.

## IV бүлек. Сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары

### <u>24 статья.</u> Сайлау берләшмәсе төшенчәсе

1. Законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән, уставында кандидатлар күрсәтү юлы белән дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда катнашуы күздә тотылган һәм сайлаулар көнен игълан иткәнчегә кадәр кимендә бер ел элек Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан теркәлгән республика сәяси җәмәгать берләшмәсе (сәяси партия, бүтән сәяси оешма, сәяси хәрәкәт) сайлау берләшмәсе була.

2. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздыру чорына төзелүче сайлау блоклары да сайлау берләшмәсе хокукларына ия булалар.

279

25 статья. Сайлау блоклары

1. Әлеге Законның 24 статьясындагы 1 пункты нигезендә сайлау берләшмәләре дип саналучы кимендә ике сәяси җәмәгать берләшмәсеннән сайлау блоклары төзелергә мөмкин.

2. Сайлау берләшмәсе сайлау блогы составына кергән очракта, ул сайлаулар үткәрү чорында мөстәкыйль сайлау берләшмәсе буларак эш итә алмый яисә башка сайлау блогына керә алмый.

3. Сайлау блогына керү турындагы карар һәр сайлау берләшмәсенең съездында (конференциясендә) кабул ителә.

4. Сайлау блоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан теркәлә. Сайлау берләшмәләренең сайлау блогына керүләре хакындагы карарлары белән сайлау берләшмәләре съездларының (конференцияләренең) беркетмәләре һәм сайлау блогын төзү турында сайлау берләшмәләренең уртак карары (аңа шушы сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре имза салырга тиеш) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылганнан соң биш көннән дә соңга калмыйча сайлау блогын теркәү уздырыла.

26 статья. Сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының вәкаләтле вәкилләре

1. Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашуларына бәйле барлык мәсьәләләр буенча, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча да, әлеге Закон нигезендә вәкаләтләр тапшырылган вәкилләрен билгеләп куялар.

2. Вәкаләтле вәкилләр сайлау берләшмәсенең яисә сайлау блогына кергән сайлау берләшмәләре вәкилләренең съезды (конференциясе) карары йә сайлау берләшмәсенең яисә сайлау блогына кергән сайлау берләшмәләре вәкилләренең шул съезды (конференциясе) вәкаләт биргән орган карары белән билгеләнәләр.

27 статья. Сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашулары

Сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә бертигез шартларда катнашалар.

280

## V бүлек. Кандидатны күрсәтү һәм теркәү

### 28 статья. Кандидатны сайлаучылар тарафыннан турыдан-туры күрсәтү

1. Турыдан-туры сайлаучылар тарафыннан кандидатлар күрсәтү үз-үзен күрсәтү юлы белән, шулай ук сайлаучы инициативасы, шул кандидатка тавыш биргәндә актив сайлау хокукына ия сайлаучылар төркеме инициативасы буенча, бу хакта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итеп, һәм алга таба кандидатларны хуплап имзалар җыю юлы белән башкарыла.

2. Кандидатны күрсәтү Татарстан Республикасы Президенты сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыкканнан соң башкарыла.

3. Татарстан Республикасының һәр гражданы яисә Татарстан Республикасының актив сайлау хокукына ия гражданнары төркеме Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыкканнан соң кандидат күрсәтү өчен сайлаучыларның инициатив төркемен төзи алалар.

4. Кандидат күрсәтү зат тарафыннан сайланырга ризалык белдерүе турында язма гариза бирү шарты белән башкарылырга мөмкин, ул гаризада биографик характердагы (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, белеме, төп эш яки хезмәт урыны (төп эш яки хезмәт урыны булмаганда - шөгыленең төре), биләгән эш урыны, кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары турында белешмә, кандидат хөкем ителгән Россия Федерациясе Җинаять кодексы статьясының (статьяларының) номеры (номерлары) һәм исеме (исемнәре), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре нигезендә кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, шул закон актларының статьясы (статьялары), гражданлыгы, шул исәптән чит ил гражданлыгы, аны алу датасы һәм нигезләре) белешмәләр күрсәтелә һәм кандидатның, сайланган очракта, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларына туры килми торган эшчәнлеген туктатырга йөкләмә алуы күрсәтелә. Әлеге гариза, имзалар җыю башлану турындагы хәбәр белән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

Шул документлар белән бергә сайлаучыларның инициатив төркеменең, сайлаучының, кандидатның вәкаләтле вәкилләре составы тапшырыла, һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

5. Сайлаучыларның инициатив төркеме, сайлаучы бары тик бер генә кандидат күрсәтергә хокуклы.

281

29 статья. Кандидатны сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан күрсәтү

1. Кандидатны сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан күрсәтү Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көннән соң башкарыла.

2. Кандидат күрсәтү турында карар сайлау берләшмәсе съездында (конференциясендә) яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3. Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы бары тик бер генә кандидат күрсәтергә хокуклы.

4. Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы әлеге сайлау берләшмәсенең, сайлау блогына кергән сайлау берләшмәләренең әгъзасы булмаган затны да кандидат итеп күрсәтергә хокуклы.

5. Сайлау блогы тарафыннан кандидат күрсәтү турындагы карар шушы блокка керүче сайлау берләшмәләре вәкилләренең съездында (конференциясендә) яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм сайлау блогына керүче сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзалана.

6. Кандидат күрсәтү зат тарафыннан сайланырга ризалык белдерүе турында язма гариза бирү шарты белән башкарылырга мөмкин, ул гаризада биографик характердагы (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, белеме, төп эш яки хезмәт урыны (төп эш яки хезмәт урыны булмаганда - шөгыленең төре), биләгән эш урыны, кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары турында белешмә, кандидат хөкем ителгән Россия Федерациясе Җинаять кодексы статьясының (статьяларының) номеры (номерлары) һәм исеме (исемнәре), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре нигезендә кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, шул закон актларының статьясы (статьялары), гражданлыгы, шул исәптән чит ил гражданлыгы, аны алу датасы һәм нигезләре) белешмәләр күрсәтелә һәм кандидатның, сайланган очракта, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларына туры килми торган эшчәнлеген туктатырга йөкләмә алуы күрсәтелә. Әлеге гариза, имзалар җыю башлану турындагы хәбәр белән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

7. Шул документлар белән бергә сайлау берләшмәсе, сайлау блогына керүче сайлау берләшмәләре уставларының күчермәләре, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының вәкаләтле вәкилләре составы тапшырыла, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының һәр вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

30 статья. Кандидатларның бертигез статусын тәэмин итү

1. Барлык кандидатлар бертигез хокукларга һәм бертигез вазыйфаларга ия булалар. Дәүләт урыннарын һәм җирле үзидарә урыннарын биләүче кандидатлар үзләренең хезмәт яисә эш урыннарыннан өстенлекле файдаланырга хокуклы түгел.

2. Әлеге Законда хезмәт яисә эш урыннарыннан өстенлекле файдалану дигәндә, түбәндәгечә аңларга кирәк:

үзләре буйсынуындагы һәм хезмәттә башкача бәйле булган затларны, бүтән дәүләт хезмәткәрләрен һәм җирле үзидарә хезмәткәрләрен эш вакытында кандидатны күрсәтүгә һәм (яисә) сайлауга ярдәм итәрлек эшчәнлек башкару өчен җәлеп итү;

дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары биләгән биналардан үзен күрсәтүгә һәм (яисә) сайлауга ярдәм итәрлек эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану, әгәр башка кандидатлар йә теркәлгән кандидатлар шундый ук шартларда бу биналардан файдалана алмасалар;

дәүләт учреждениеләренең яисә җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген тәэмин итүче телефон, факсимиль һәм башка төр элемтәләрдән, мәгълүмати хезмәт күрсәтүләрдән, оештыру техникасыннан имзалар җыюны һәм сайлау алды үгетләвен алып бару өчен файдалану;

дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге транспорт чараларыннан үзен күрсәтүгә һәм (яисә) сайлауга ярдәм итәрлек эшчәнлекне башкару өчен түләүсез яисә ташламалы шартларда файдалану. Әлеге нигезләмә дәүләт саклавы турындагы законнар нигезендә күрсәтелгән транспортлардан файдаланучы затларга кагылмый;

хезмәт (дәүләт акчалары яисә җирле үзидарә акчалары исәбеннән түләнүче) командировкалары барышында дәүләт хезмәткәрләре яисә җирле үзидарә хезмәткәрләре тарафыннан имзалар җыюны, сайлау алды үгетләвен башкару;

имзалар җыюны һәм сайлау алды үгетләвен башкару максатларында әлеге Законның 38 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларыннан өстенлекле файдалану (башка кандидатлар, теркәлгән кандидатлар белән чагыштырганда).

Югарыда санап кителгән чикләүләрне үтәү депутатлар, сайланып куелучы урындагы затлар тарафыннан сайлаучылар каршында үз вазыйфаларын үтәргә комачаулык итмәскә тиеш.

31 статья. Кандидатны яклап имзалар җыю

1. Кандидатларны күрсәтү турындагы карарлар әлеге Законның 3 статьясы нигезендә актив сайлау хокукына ия булган кимендә 50 мең Татарстан Республикасы гражданының имзаларын җыю юлы белән хупланырга тиеш.

2. Имзалар кәгазе әлеге Законның 1 һәм 2 кушымталарында күрсәтелгән рәвештә әзерләнә.

3. Кандидатны хуплап имзалар җыйганда һәр имза кәгазендә кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, эш урыны, билгән урыны (шөгыленең төре) һәм яшәү урыны күрсәтелә.

4. Кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, имзалар кәгазендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелә. Кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, имзалар кәгазендә тиешле чит илнең исеме күрсәтелергә тиеш.

5. Сайлаучы имзалар кәгазендә имза сала, анда ул фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урынының адресын, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм аның бирелү датасын, шулай ук имза салу датасын күрсәтә. Кандидатны хуплап үз имзаларын салган сайлаучылар турындагы белешмәләр кандидатны хуплап имзалар җыйган зат тарафыннан имзалар кәгазенә кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән белешмәләр кулдан язылып кертелә.

6. Имзалар кәгазе имзалар җыючы зат тарафыннан, фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелгән килеш, һәм вәкаләтле вәкил тарафыннан, шул ук белешмәләр күрсәтелгән килеш, таныклана. Һәр имза кәгазендә сайлаучыларның имзаларын җыйган Татарстан Республикасы районының, шәһәренең, шәһәрдәге районының исеме күрсәтелергә тиеш.

7. Сайлаучыларның имзаларын җыю эш (шул исәптән хезмәт коллективларында), хезмәт, уку, яшәү урыннарында, шулай ук үгетләү һәм имзалар җыю законда тыелмаган башка урыннарда уздырыла. Барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар администрацияләренең имзалар җыюда катнашуы, шулай ук имзалар җыю процессында мәҗбүр итү һәм имзалар биргән өчен сайлаучыларны бүләкләү рөхсәт ителми. Хезмәт хакы түләү процессында һәм урыннарында имзалар җыю рөхсәт ителми. Мондый тыюларны тупас итеп яисә берничә тапкыр бозу җыелган имзаларны гамәлгә яраксыз дип тану һәм (яисә) кандидатны теркәүдән баш тарту, теркәлгән кандидатны теркәүне юкка чыгару өчен нигез булырга мөмкин.

8. Татарстан Республикасының хокуктан файдалануга сәләтле балигъ гражданы сайлаучылар имзаларын җыю хокукына ия була. Кандидат, сайлау

берләшмәсе, сайлау блогы сайлаучыларның имзаларын җыюны уздыручы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзи алалар. Әлеге эш өчен түләү бары тик кандидатның сайлау фонды аша гына башкарыла.

9. Бер үк кандидатны күрсәтүче һәм аны күрсәтү турында Үзәк сайлау комиссиясенә язмача хәбәр итүче һәр сайлау берләшмәсе, сайлау блогы, сайлаучыларның инициатив төркеме, сайлаучы, күрсәтелүчене хуплап, кирәк кадәр сайлаучылар имзаларын җыя. Кандидатны күрсәтүче төрле инициаторлар тарафыннан бер үк кандидатны хуплап җыелган сайлаучыларның имзаларын бергә кушу рөхсәт ителми.

10. Имзалар җыю тәмамланганнан соң сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының, сайлаучыларның инициатив төркеменең, сайлаучының һәм кандидатның вәкаләтле вәкилләре сайлаучыларның җыелган имзаларын саныйлар. Санау нәтиҗәләре буенча сайлаучылар имзаларын җыю йомгаклары турында беркетмә төзелә, ул вәкаләтле вәкилләр тарафыннан имзалана.

11. Татарстан Республикасы Президентын вакытыннан алда яисә кабат сайлауларны уздырган очракта, әлеге статьяның 1 пункты нигезендә җыелырга тиешле сайлаучылар имзаларының саны яртыга кими.

<u>32 статья.</u> Кандидатны теркәү

1. Кандидатны теркәү өчен кандидат үзе яисә сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының, сайлаучыларның инициатив төркеменең, сайлаучының вәкаләтле вәкиле тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә түбәндәге сайлау документларын тапшыралар:

а) кандидат күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары җыелган имза кәгазьләре;

б) сайлаучылар имзаларын җыю йомгаклары турында беркетмә;

в) кандидатның сайланырга ризалык белдерүе турында, әлеге Законның 28 статьясындагы 4 пункты, 29 статьясындагы 6 пункты нигезендә төзелгән гаризасы.

2. Кандидатны теркәү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук кандидатның керемнәре һәм милек хокукындагы мөлкәте турында белешмәләр тапшырылырга тиеш. Керемнәрнең күләме һәм чыганаклары турындагы белешмәләр кандидат булган гражданның Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү елы алдындагы керемнәре турында декларация күчермәсе рәвешендә (салым органнары тамгасы белән) тапшырыла. Кандидат булган граждан салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә керемнәр турында декларация тапшырырга тиеш булмаган очракта, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү елы алдындагы ел керемнәренең гомуми күләме турында керемнәр алган урындагы оешмадан белешмә тапшырыла.

Кандидатның милек хокукындагы мөлкәте турындагы белешмәләр әлеге Законның 3 нче кушымтасында билгеләнгән рәвештә тапшырыла.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статья нигезендә тапшырылучы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турындагы тәкъдим белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Кандидатны теркәү өчен аны хуплап җыелган һәм тапшырылган имзаларның саны теркәү өчен кирәкле имзалар саныннан артып китәргә мөмкин, әмма ул 15 проценттан да артык булмаска тиеш.

5. Барлык тапшырылган имзалар йә тикшерү өчен очраклы (шобага салу юлы белән) сайланып алынган имзаларның бер өлеше (әмма ул теркәлү өчен кирәкле имзалар санының 20 процентыннан да ким булмаска тиеш) тикшерелергә мөмкин. Тикшерелүче имзалар арасында тикшерелгән имзалар санынннан 15 проценттан артыграгы дөрес түгел дип табылганда яисә тиешле кандидатны теркәү өчен дөрес имзалар саны җитәрлек булмаганда, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәүдән баш тарта.

6. Кандидатны теркәү өчен билгеләнгән санда имзалар тапшырган барлык кандидатларга һәр тикшерелгән очрак турында хәбәр ителергә тиеш. Һәр сайлау берләшмәсе, сайлау блогы, кандидат тарафыннан тапшырылган имзаларны тикшерүне уздырганда, тикшерү өчен имзалар сайлап алуны да кертеп, билгеләнгән санда имзалар тапшырган барлык кандидатлар, кандидатларның, кандидатларны күрсәткән сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының вәкилләре, кандидатны күрсәтү инициативасын башкаручы сайлаучыларның вәкилләре катнашырга хокуклы.

7. Имза кәгазьләрендәге, әмма Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә имзалар тапшырганга кадәр кандидатны күрсәтү инициаторлары тарафыннан төшереп калдырылган (сызылган) һәм алар тарафыннан махсус тамга куелган имзалар тикшерелмиләр һәм исәпкә алынмыйлар.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе 5 көн эчендә кандидатны күрсәтү тәртибенең әлеге Закон таләпләренә туры килүен тикшерергә һәм кандидатны теркәү турында йә теркәүдән баш тарту турында карар кабул итәргә тиеш.

9. Кандидатны теркәүдән баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәүдән баш тарту турында карар кабул ителгән мизгелдән бер тәүлек эчендә кандидатка йә кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының, сайлаучыларның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиленә, баш тарту нигезләрен бәян итеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарының күчермәсен бирергә тиеш. Баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булырга мөмкин:

имзалар җыюның әлеге Законда билгеләнгән тәртибен җитди бозу;

сайлаучыларның кандидатны хуплап җыелган һәм тапшырылган дөрес имзаларының саны җитәрлек булмау яисә тикшерелгән имзалар арасында дөрес булмаган имзаларның өлеше билгеләнгән чикләрдән артып китү;

әлеге Законның 28 статьясындагы 4 пункты, 29 статьясындагы 6 пункты һәм әлеге статьяның 2 пункты нигезендә кандидат тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөрес булмавы, әгәр бу белешмәләрнең дөрес булмавы җитди үзенчәлеккә ия булса;

сайлау фондын төзү һәм аның акчаларын тоту тәртибен җитди бозу;

әлеге Законда каралган бүтән нигезләр.

10. Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан күрсәтелгән кандидатны теркәгәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарында тиешле сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан аны күрсәтү факты билгеләнә. Сайлаучылар тарафыннан күрсәтелгән кандидат тавыш бирү көненә кадәр кимендә бер ел кала законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бары тик бер генә җәмәгать берләшмәсенә караганлыгы турында һәм бу берләшмәдәге үз статусы турында хәбәр итәргә хокуклы.

11. Теркәлгән һәр кандидатка теркәлүнең датасы һәм вакыты күрсәтелгән теркәлү таныклыгы тапшырыла. Теркәлгән кандидатлар турында белешмәләр кандидатларны теркәгәннән соң ике тәүлек эчендә массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

12. Әгәр әлеге Законның 28 статьясындагы 4 пункты, 29 статьясындагы 6 пункты һәм әлеге статьяның 2 пункты нигезендә кандидат тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөрес түгеллеге кандидатны теркәгәннән соң ачыкланса һәм әлеге мәгълүматларның дөрес түгеллеге җитди үзенчәлеккә ия булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 16 көннән дә соңга калмыйча тиешле кандидатны теркәүне гамәлдән чыгару турында карар кабул итәргә, ә тавыш бирү көненә кадәр 15-1 көннән дә соңга калмыйча әлеге кандидатны теркәүне гамәлдән чыгару турындагы тәкъдим белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

13. Кандидат теләсә кайсы вакытта, әмма тавыш бирү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча, үз кандидатурасын кире алырга хокуклы. Әгәр бу аны мәҗбүр итмичә эшләнсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аның счетына сайлауларны әзерләү һәм уздыру буенча ул тоткан чыгымнарның тиешле өлешен, сайлау алды үгетләвенә бүлеп бирелгән акчаларны да кертеп, күчерә.

14. Әгәр теркәгәннән соң һәм тавыш бирү көненә кадәр икедән дә кимрәк кандидат калса, өстәмә рәвештә кандидатлар тәкъдим итү һәм тиешле сайлау гамәлләрен тормышка ашыру өчен сайлаулар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан 75 көнгә кичектерелә.

## V бүлек. Теркәлгән кандидатның статусы

### 33 статья. Теркәлгән кандидатлар хокукларының һәм бурычларының бертигез булуы

Теркәлгән барлык кандидатлар да, әлеге Законда билгеләнгән очраклардан гайре, бертигез хокукларга һәм бурычларга ия.

### 34 статья. Теркәлгән кандидатның хокуклары һәм бурычлары

1. Теркәлгәннән соң кандидатлар теркәлгән көннән башлап сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр шушы чор эчендә теләсә кайсы көндә һәм теләсә кайсы вакытта шәхси гаризалары, рапортлары буенча эштән, хезмәттән һәм хәрби җыелулардан азат ителергә мөмкин. Шушы вакыт эчендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән теркәлгән кандидатка аның уртача айлык кереме күләмендә акчалата компенсация түли, ул сайлаулар көненә Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменнән артмаска тиеш.

2. Теркәлгән кандидат теркәлгән көннән башлап сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр администрация (эш бирүче) инициативасы белән эштән азат ителә алмый, аның ризалыгыннан башка бүтән эшкә яисә хезмәт урынына күчерелә, шул исәптән башка җиргә эшкә күчерелә, шулай ук командировкага җибәрелә алмый. Теркәлгән кандидатның сайлауларда катнашкан вакыты кандидат булып теркәлгәнгә кадәр эшләгән белгечлеге буенча хезмәт стажына кертеп санала.

3. Теркәлгән кандидат Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә гомуми кулланылыштагы теләсә нинди транспорт чараларыннан, таксидан һәм заказ рейсларыннан гайре, файдаланганда транспорт чыгымнарын түләттерергә хокуклы. Мондый чакта теркәлгән кандидатка шәһәр яны транспортында (15 тапкырдан да артык түгел) һәм халыкара транспортта (сайланырга ризалык белдерү турындагы гаризада күрсәтелгән яшәү урыныннан Татарстан Республикасының административ-территория берәмлеге үзәгенә кадәр һәм кире кайту - 43 тапкырдан да артык түгел) йөргәндә юл йөрү билетлары хакы, юл йөрү билетларын күрсәтеп, шулай ук шәһәр транспортында йөргәндә юл йөрү билетлары хакы, тиешле чорга юл йөрү билетларын күрсәтеп, түләнә.

4. Теркәлгән кандидатның 20 гә кадәр ышанычлы заты булырга мөмкин, алар кандидатның һәм ышанычлы зат булырга ризалык белдергән гражданның язма гаризалары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан теркәләләр. Ышанычлы затлар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән таныклык алалар һәм теркәлгән

кандидатның сайлануына ярдәм итә торган үгетләүне һәм бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашыралар, дәүләт һәм җәмәгать берләшмәләре белән үзара мөнәсәбәтләрдә, шулай ук сайлау комиссияләрендә аның мәнфәгатьләрен чагылдыралар. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән чорга администрация (эш бирүчеләр) ышанычлы затларга аларның үтенече буенча түләүсез ял бирергә тиеш. Ышанычлы затларын билгеләгән теркәлгән кандидатлар, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итеп, аларны теләсә кайсы вакытта кире чакыртып алырга хокуклы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе бу ышанычлы затларга бирелгән таныклыкларны юкка чыгара.

5. Теркәлгән кандидат, Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка, җинаять җаваплылыгына җәлеп ителми, кулга алынмый яисә хөкем итү тәртибендә билгеләнә торган административ җәза чараларына тартылмый. Татарстан Республикасы Прокуроры мондый ризалык бирүе турында кичекмәстән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

6. Дәүләт хезмәтендәге яисә җирле үзидарә органнары хезмәтендәге йә массакүләм мәгълүмат чараларында эшләүче теркәлгән кандидат сайлауларда катнашу вакытына хезмәт вазыйфаларын үтәүдән азат ителә. Теркәлгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тиешле боерыкның (күрсәтмәнең) таныкланган күчермәсен тапшыра һәм ул үзенең эш яисә хезмәт урынындагы өстенлекләрдән файдаланырга хокуксыз була.

7. Яңа чорга сайланучы Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы һәм теркәлгән кандидат булып торучы Татарстан Республикасы Премьер-министры үз вәкаләтләрен үтәүне дәвам итә, әмма ул үзенең хезмәт урынындагы өстенлекләрдән файдаланырга хокуксыз була.

8. Кандидат тарафыннан әлеге Закон таләпләре бозылганда, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аны язма рәвештә кисәтә, ә кабат бозылганда, әлеге кандидатны теркәү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга мөмкин, бу хакта сайлаучыларга һәм кандидатка җиткерелә.

## VII бүлек. Сайлау алды үгетләве

### 35 статья. Сайлау алды үгетләве һәм аны алып бару рәвешләре

1. Сайлау алды үгетләве түбәндәгечә алып барылырга мөмкин:

а) телерадиотапшырулар оешмалары каналлары аша һәм вакытлы матбугат басмаларында;

289

б) массакүләм гамәлләр (җыелышлар һәм гражданнар белән очрашулар, митинглар, демонстрацияләр, урамда йөрүләр, гавами дебатлар һәм дисскусияләр) үткәрү юлы белән;

в) басма, аудиовизуаль һәм башка төр үгетләү материалларын бастырып чыгару һәм тарату юлы белән;

г) закон тарафыннан тыелмаган башка рәвешләрдә.

2. Телерадиотапшырулар оешмалары, каналлары аша һәм вакытлы матбугат басмаларында сайлау алды үгетләве гавами дебатлар, дискуссияләр, «түгәрәк өстәлләр», матбугат конференцияләре, интервьюлар, чыгышлар, сәяси рекламалар, теркәлгән кандидат турында телеочерклар, видеофильмнар күрсәтү юлы белән һәм закон белән тыелмаган башка рәвешләрдә алып барыла. Мондый чакта теркәлгән кандидат үзенең сайлау алды үгетләвенең рәвешен һәм характерын мөстәкыйль рәвештә сайлап алырга хокуклы. Телерадиотапшырулар оешмалары каналлары аша һәм вакытлы матбугат басмаларында сайлау алды үгетләве алып бару теркәлгән кандидатларның тиешле сайлау фондларыннан түләнергә тиеш, моңа теркәлгән кандидатларга эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бушлай бирү очраклары керми.

3. Түбәндәгеләргә сайлау алды үгетләве алып бару, теләсә нинди сайлау алды үгетләү материаллары бастырып чыгару һәм тарату тыела:

а) дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына;

б) дәүләт эш урыннарын биләүче һәм җирле үзидарә эш урыннарын биләүче затларга, дәүләт хезмәткәрләренә һәм җирле үзидарә хезмәткәрләренә, хәрби хезмәткәрләргә үзләренең эш яисә хезмәт вазыйфаларын башкарганда эш яки хезмәт урыннарындагы өстенлекләрдән файдаланырга;

в) хәрби частьләргә, хәрби учреждениеләргә һәм оешмаларга;

г) хәйрия оешмаларына һәм дини берләшмәләргә, шулай ук алар гамәлгә куйган оешмаларга;

д) сайлау комиссияләренә, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына.

<u>36 статья.</u> Сайлау алды үгетләвен алып бару чорлары

1. Сайлау алды үгетләве кандидатны теркәү көненнән башлана һәм тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала ноль сәгатьтә туктатыла.

2. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү (уздыру) турындагы карарны рәсми бастырып чыгарган көннән алып кандидатны теркәү мизгеленә кадәр, шулай ук тавыш бирү көнендә һәм аңа кадәрге көндә сайлау алды үгетләве тыела.

3. Сайлау комиссияләре биналарыннан һәм йортларыннан читтә законда билгеләнгән тәртиптә элек эленгән сайлау алды басма үгетләү

230

материаллары (листовкалар, плакатлар һәм башкалар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда саклана.

4. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта сайлау алды үгетләве Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кабат тавыш бирүне билгеләү турындагы карары рәсми басылып чыгу көненнән яңартыла һәм кабат тавыш бирү көненә бер тәүлек кала ноль сәгатьтә туктатыла.

37 статья. Җәмәгать фикерен сораштырулар

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга бәйле җәмәгать фикерен сораштыруларның нәтиҗәләрен бастырып чыгарганда (халыкка игълан иткәндә) массакүләм мәгълүмат чаралары сораштыруны үткәргән оешманы, аны үткәрүнең вакытын, сораштырылганнарның санын (аралап), мәгълүмат җыю ысулын, сораштыруның урынын, сорауның төгәл формулировкасын, мөмкин төгәлсезлекләрнең статистик бәясен күрсәтергә тиеш.

2. Тавыш бирү көненә кадәр өч көн дәвамында, шулай ук тавыш бирү көнендә җәмәгать фикерен сораштыруларның нәтиҗәләрен, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре фаразларын массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару (халыкка игълан итү), сайлауларга бәйле башка төрле тикшеренүләр рөхсәт ителми.

38 статья. Телерадиотапшырулар оешмалары каналлары аша һәм вакытлы матбугат басмаларында сайлау алды үгетләве үткәрүнең гомуми шартлары

1. Телерадиотапшырулар оешмалары каналлары аша эфир вакыты һәм вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданы теркәлгән кандидатларга Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсендә каралган тәртиптә түләүсез (түләүсез эфир вакыты, түләүсез матбугат мәйданы) яисә түләүле бирелергә мөмкин.

2. Гамәлгә куючылары (гамәлдә куюда катнашучылары) дәүләт органнары, оешмалары, учреждениеләре булган һәм (яисә) телерадиотапшыруны гамәлгә ашыручы тиешле оешмаларның, тиешле вакытлы матбугат басмасы редакцияләренең Татарстан Республикасы Президенты сайлауларын билгеләү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару көненә кадәрге ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән бюджетның кимендә 15 проценты финанслана торган оешмалар, учреждениеләр теркәлгән кандидатларга сайлау алды үгетләвен алып бару өчен бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш.

3. Телерадиотапшыруларның дәүләткә карамаган оешмалары һәм дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре теркәлгән

291

кандидатларга эфир вакытын, матбугат мәйданын түләүле рәвештә бирергә хокуклы. Эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгән очракта алар өчен түләү күләме һәм шартлары эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирелгән теркәлгән барлык кандидатлар өчен бердәй булырга тиеш.

4. Эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләүнең күләме һәм шартлары турындагы белешмәләр телерадиотапшыруның тиешле оешмасы, вакытлы матбугат басмасының тиешле редакциясе тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 3 көннән дә соңга калмыйча бастырылып чыгарылырга тиеш һәм, теркәлгән кандидатларга эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүгә әзерлек турындагы хәбәр белән, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

5. Эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләү теркәлгән кандидатның сайлау фонды акчалары исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.

<u>39 статья.</u> Массакүләм гамәлләр ярдәмендә үгетләү алып бару шартлары

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына, сайлаучылар төркемнәренә һәм аларның ышанычлы затларына сайлау алды җыелышлары, сайлаучылар белән очрашулар, гавами дебатлар һәм дискуссияләр, митинглар, демонстрацияләр һәм урам йөрүләр оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм итәргә, массакүләм гамәлләр үткәргәндә иминлекне тәэмин итәргә тиеш.

2. Теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының ышанычлы затлары сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен биналар бирү турындагы гариза бирелгән көннән соң өч көн дәвамында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан карала.

3. Сайлау комиссияләренең гаризалары буенча сайлау алды массакүләм гамәлләрен үткәрү өчен яраклы һәм дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге биналар сайлаучылар белән теркәлгән кандидатларның, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары вәкилләренең һәм аларның ышанычлы затларының очрашулары өчен сайлау комиссиясе билгеләгән вакытка милекче һәм биләүче тарафыннан файдалануга бушлай тапшырыла.

Әгәр күрсәтелгән бина, шулай ук үзенең устав (тупланма) капиталында сайлауларны билгеләү (үткәрү) турындагы карарны рәсми бастырып чыгарган көнгә дәүләт өлешенең һәм (яисә) җирле үзидарә өлешенең 30 процентан артыгына ия булучы оешма милкендәге бина массакүләм гамәлләр үткәрү өчен теркәлгән кандидатларның берсенә яисә аның ышанычлы затына, сайлау берләшмәсенә, сайлау блогына бирелгән булса,

бина милекчесенең, хуҗасының башка теркәлгән кандидатка яисә аның урындагы затына, сайлау берләшмәсенә, сайлау блогына шундый ук шартларда бина бирүдән баш тартырга хокукы юк. Сайлау комиссияләре теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары өчен массакүләм гамәлләр үткәргәндә бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш.

4. Кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары вәкилләре сайлаучылар - хәрби частьтән читтәге хәрби хезмәткәрләр белән очрашулар үткәргәндә барлык кандидатларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына бертигез шартлар тәэмин ителә.

<u>40 статья.</u> Басма үгетләү материалларын бастырып чыгару һәм тарату шартлары

1. Теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары законнарда билгеләнгән тәртиптә басма үгетләү материалларын бастырып чыгарырга хокуклы.

2. Барлык басма үгетләү материалларында әлеге материалларны әзерләгән оешмаларның исемнәре һәм адреслары (затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, яшәү урыннары), әлеге материалларга заказ биргән оешманың исеме (затның фамилиясе, исеме, атасының исеме) шулай ук аларның тиражы һәм бастырып чыгару датасы турында мәгълүмат булырга тиеш.

3. Басма үгетләү материалларының нөсхәләре яисә аларның күчермәләре, таратыла башланганчыга кадәр, теркәлгән кандидат тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә яисә территория сайлау комиссиясенә бирелергә тиеш. Күрсәтелгән материаллар белән бергә сайлау комиссиясенә, шулай ук әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урынындагы адресы турында) белешмәләр бирелергә тиеш. Басма үгетләү материалларын тиешле теркәлгән кандидатның язма рәвештәге ризалыгыннан башка әзерләүгә, таратуга юл куелмый.

4. Басма үгетләү материалларын әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән таләпләрне бозып тарату тыела.

5. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә территория сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча һәр сайлау участогы территориясендә басма үгетләү материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм аларны җиһазландырырга тиеш. Теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына басма үгетләү материалларын урнаштыру өчен бертигез шартлар тәэмин ителергә тиеш.

6. Басма үгетләү материаллары биналарда, йортларда, корылмаларда һәм башка объектларда күрсәтелгән объектлар милекчеләренең яисә

биләүчеләренең ризалыгы белән эленергә мөмкин. Күрсәтелгән материалларны һәйкәлләргә, обелискларга һәм тарихи, мәдәни яисә архитектура кыйммәте булган биналарга, шулай ук сайлау комиссияләре биналарында, аларга керү урыннарында һәм тавыш бирү биналарында элү тыела.

7. Ялган басма үгетләү материалларын тарату турында яисә басма үгетләү материалларын әлеге статья таләпләрен бозып тарату турында хәбәр алган сайлау комиссиясе әлеге эшчәнлекне туктату буенча чаралар күрә һәм хокукка каршы үгетләү эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә белән һәм законсыз басма үгетләү материалларын алу турында хокук саклау органнарына, бүтән органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

41 статья. Сайлау алды үгетләвен үткәрү хокукыннан явыз ниятләрдә файдалануга юл куймау

1. Сайлау алды үгетләвен үткәргәндә түбәндәге ирекле массакүләм мәгълүматтан явыз ниятләрдә файдалануга юл куелмый: социаль, раса, милли, дини нәфрәтне һәм дошманлыкны уятучы үгетләү, хакимият алуга, конституциячел корылышны көч кулланып үзгәртүгә һәм дәүләтнең бөтенлеген җимерүгә өндәү, сугышны пропагандалау һәм ирекле массакүләм мәгълүмат чараларыннан явыз нияттә файдаланунын законнар белән тыелган башка төрле рәвешләре.

2. Сайлау комиссияләре сайлау алды үгетләвен үткәрүнең билгеләнгән тәртибен саклауны контрольдә тоталар.

3. Сайлаучыларга түләүсез яисә өстенлекле ташламалы шартларда товарлар, хезмәт күрсәтүләр (мәгълүмат хезмәт күрсәтүләреннән гайре), кыйммәтле кәгазьләр биреп, шулай ук акча түләп, сайлау алды үгетләве үткәрү тыела.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең журналистларына, башка иҗади хезмәткәрләренә, шулай ук урындагы затларына, телевидение һәм (яисә) радио тапшыруларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларының урындагы затларына һәм иҗади хезмәткәрләренә, әгәр күрсәтелгән затлар кандидатлар йә кандидатларның урындагы затлары булып торсалар, массакүләм мәгълүмат чаралары аша сайлау кампаниясен яктыртуда катнашу тыела.

## VIII бүлек. Сайлауларны финанслау

42 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру буенча сайлау комиссияләренең чыгымнары, шулай ук сайлау

комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итү буенча чыгымнар аларның вәкаләтләр чоры дәвамында Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнә, анда тиешле чыгымнар аерым юл булып карала.

2. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздыру өчен Татарстан Республикасының республика бюджетында каралган акчалар сайлаулар көнен билгеләгәннән соң ун көн эчендә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе карамагына тапшырыла һәм ул аны сайлау комиссияләренә бүлеп бирә.

3. Сайлау комиссияләренә счетлар ачу һәм алып бару, исәпкә алу, хисаплылык һәм акча күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Сайлау комиссияләренең рәисләре Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү өчен бүлеп бирелгән акчалар белән эш итәләр һәм сайлау комиссияләренең финанс мәсьәләләре хакындагы карарларына финанс документларының туры килү-килмәве һәм күрсәтелгән акчаларны тоту турында финанс хисаплары бирү буенча җаваплы булалар. Бюджетның файдаланылмаган акчалары, сайлаулар узгач, әлеге статьяның 1 пунктында каралган максатларда файдалану өчен сайлау комиссияләренең махсус счетларында кала.

<u>43 статья.</u> Кандидатның сайлау фонды

1. Кандидат Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә сайлаучыларның имзаларын җыя башлау турында язма рәвештә хәбәр иткәннән соң сайлау алды үгетләвен финанслау өчен үз сайлау фондын төзергә тиеш. Теркәлгән кандидатлар үз сайлау кампанияләрен, шул исәптән сайлау алды үгетләвен финанслау өчен үзләренең сайлау фондларының ачык счетларын алып баруны дәвам итәләр.

2. Сайлау фондын тәшкил итүче акчалар Россия Федерациясе Саклык банкының «Татарстан» банкы бүлегенә махсус счетка күчереләләр. Әлеге счет кандидат тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рөхсәте белән ачыла.

3. Күрсәтелгән счетларны ачу һәм алып бару тәртибе, сайлау фонды акчалары буенча исәпкә алу һәм хисаплылык тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Сайлау фонды акчаларын күрсәтелгән максатларда тоту хокукы шушы фондны төзегән кандидатка бирелә.

5. Кандидатларның сайлау фондлары түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

кандидатны теркәгәннән соң Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кандидатка бүлеп бирелгән акчалар;

кандидатның үз акчалары, аларның җыелмасы Татарстан Республикасы Президенты сайлауларын билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь күләменнән 150 тапкырдан да арта алмый, кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен 200 тапкырдан да арта алмый;

кандидатка үзен күрсәткән сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан бүлеп бирелгән һәм барысы бергә Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән күләменнән 15 мең тапкырдан арта алмаган акчалар;

гражданнарның һәм юридик затларның Татарстан Республикасы Президенты сайлауларын билгеләү турында рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь күләменең һәр граждан өчен 30 тапкырдан һәм һәр юридик зат өчен 3 мең тапкырдан артмаган ихтыярый иганәләре.

6. Кандидатның сайлау фонды акчалары исәбеннән чыгымнарының иң чик суммасы Татарстан Республикасы Президенты сайлауларын билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән 20 минималь күләменнән 20 мең тапкырга арта алмый.

7. Сайлау фондларына түбәндәгеләрдән иганә алу рөхсәт ителми:

Россия Федерациясенең 18 яше тулмаган гражданнарыннан;

сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә устав (тупланма) капиталында дәүләт өлеше яисә җирле үзидарә өлеше 30 проценттан артык булган юридик затлардан;

тавыш бирү көненә кадәр кимендә бер ел эчендә теркәлгән юридик затлардан;

чит илләрдән, чит ил юридик затларыннан һәм гражданнарыннан;

гражданлыксыз затлардан;

чит ил катнашындагы Россия юридик затларыннан, әгәр сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә чит ил капиталы өлеше аларның устав (тупланма) капиталында 30 проценттан артып китсә;

халыкара оешмалардан һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләрдән;

дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан, җирле үзидарә учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан;

хәрби частьләрдән, хәрби учреждениеләрдән һәм оешмалардан, хокук саклау органнарыннан;

хәйрия оешмаларыннан һәм дини берләшмәләрдән, алар гамәлгә куйган оешмалардан;

аноним иганәчеләрдән (гражданнар өчен - түбәндәге белешмәләрнең теләсә кайсын күрсәтмичә: фамилиясен, исемен, атасының исемен, торган жиренең адресын һәм туган көнен; юридик затлар өчен - түбәндәге белешмәләрнең теләсә кайсын күрсәтмичә: салым түләүченең идентификация номерын, исемен, теркәү көнен, банк реквизитларын, устав (тупланма) капиталында дәүләт өлешенең яисә җирле үзидарә өлешенең юклыгы яисә, андый өлешнең күләмен күрсәтеп, барлыгы турында, устав (тупланма) капиталында чит илнең катнашмавы хакында яисә, катнашу өлешен күрсәтеп, аның күләме турында).

6. Сайлау фондларының акчалары максатчан билгеләнешкә ия. Алар бары тик сайлау компанияләре үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауда гына файдаланыла алалар. Сайлау фондларының акчалары түбәндәгеләргә файдаланылырга мөмкин:

а) кандидатны күрсәтүне хуплап, сайлаучыларның имзаларын җыюга юнәлдерелгән оештыру-техник чараларны финанс ягыннан тәэмин итүгә, шул исәптән сайлаучыларның имзаларын җыю өчен җәлеп ителгән затларның хезмәтләре өчен түләүгә;

б) сайлау алды үгетләвенә, шулай ук мәгълүмати һәм консультацион характердагы эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә;

в) юридик затлар яисә гражданнар тарафыннан башкарылган (күрсәтелгән) башка эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә, шулай ук сайлау компаниясен үткәрүгә турыдан-туры бәйле башка чыгымнарга.

7. Кандидатларга, теркәлгән кандидатларга сайлаучыларның имзаларын җыю, сайлау алды үгетләве алып бару, башка сайлау алды гамәлләрен башкару буенча эшләргә түләү өчен бүтән төрле акчалардан файдалану тыела, моңа аларның сайлау фондларына алынган акчалары керми.

8. Әгәр кандидат, теркәлгән кандидат имзалар җыйганда яисә сайлау алды үгетләве алып бару, башка төрле сайлау алды гамәлләрен башкару чорында үз сайлау фонды акчаларыннан гайре башка акчалардан файдаланса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәү турындагы карарын юкка чыгарырга хокуклы.

9. Кандидатның, теркәлгән кандидатның сайлау фонды счетын тотучы банк таләбе буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе даими рәвештә аңа әлеге кандидатның, теркәлгән кандидатның сайлау счетындагы акчаларының кереме һәм чыгымы турында мәгълүмат бирергә тиеш.

10. Кандидатларның үз сайлау фондларын төзү өчен ачыла торган махсус счетлары буенча башкарылучы барлык финанс гамәлләре сайлаулар көнендә туктатыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайлаулар көненә кадәр башкарылган чыгымнарны түләү буенча финанс гамәлләрен башкару вакытын кандидатның үтенечнамәсе нигезендә озайта ала.

<u>44 статья.</u> Акчаларны исәпкә алу тәртибе һәм финанс хисабы

1. Кандидат, теркәлгән кандидат, сайлауларның нәтиҗәләре басылып чыкканнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә үз фондын төзүнең барлык күләмнәре һәм чыганаклары турында, шулай ук барлык башкарылган чыгымнар турында финанс хисабы бирәләр. Күрсәтелгән финанс хисапларының күчермәләре алынганнан соң 3 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

2. Участок сайлау комиссияләре, сайлауларның нәтиҗәләре басылып чыккан көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләренә финанс хисаплары тапшыралар.

3. Территория сайлау комиссияләре, сайлау иәтиҗәләре басылып чыккан көннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә финанс хисаплары тапшыралар.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән соң өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президенты сайлауларына Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын тоту турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына финанс хисабы тапшыра.

<u>45 статья.</u> Сайлау фондларының тотылмый калган акчалары турында

Кандидат, теркәлгән кандидат махсус счетларындагы тотылмый калган акчаларын иганәләр кертүче яисә акча күчерүче оешмаларның һәм затларның счетларына салынган акчаларга пропорциональ рәвештә күчерергә тиеш. Тавыш бирү көненнән соң 30 көн узгач, банк Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе биргән язма күрсәтмә буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тия торган акча өлешен аның счетына бәхәссез рәвештә күчерергә тиеш. Кандидатның, теркәлгән кандидатның махсус счетында калган башка акчаларны, тавыш бирү көненнән соң 60 көн узгач, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенең язма күрсәтмәсе буенча банк Татарстан Республикасы республика бюджеты кеременә күчерергә тиеш.

<u>46 статья.</u> Контроль-ревизия хезмәте

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга әзерләнү һәм аларны уздыру өчен сайлау комиссияләренә бүлеп бирелгән акчаларның максатчыл тотылышын контрольдә тоту өчен, шулай ук акчаларның керү чыганакларын, сайлау фондлары акчаларын исәпкә алуның, файдалануның

дөреслеген һәм кандидатлар, теркәлгән кандидатлар тарафыннан аларның дөрес тотылышын, финанс хисапларын тикшерү өчен, дәүләт органнарының һәм башка органнарның, учреждениеләрнең белгечләрен җәлеп итеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча, сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне 4 айдан да артык булмаган чорга аның карамагына җибәрергә тиеш. Бу чор дәвамында белгечләр, төп эшләреннән вакытлыча азат ителеп, үз вазыйфаларын башкаралар, алар өчен төп эш урыны буенча билгеләнгән хезмәт хаклары һәм түләүләр саклана.

## IX бүлек. Тавыш бирү һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү

47 статья. Тавыш бирү бинасы

1. Тавыш бирү бинасы тиешле җирле хакимият башлыгы тарафыннан участок сайлау комиссиясе карамагына түләүсез бирелә.

2. Тавыш бирү бинасында яшерен тавыш бирү өчен кирәк санда кабиналар яисә бүлмәләр булырга, сайлау бюллетеньнәре бирү урыннары билгеләнергә тиеш. Яшерен тавыш бирү кабиналарына яисә бүлмәләренә яктырту системасы, өстәлләр һәм язу әсбаплары куела. Әлеге максатлар өчен карандашлар куллану рөхсәт ителми.

3. Тавыш бирү өчен сайлау әрҗәләре тавыш бирүчеләр аңа якынлашканда яшерен тавыш бирү кабиналары яисә бүлмәләре аша чыгарлык итеп урнаштырылалар. Тавыш бирүче тарафыннан тавыш бирү кабинасында яисә бүлмәсендә сайлау бюллетене тутырылудан гайре, тавыш бирү барышы тулысынча участок сайлау комиссиясе әгъзалары, күзәтүчеләре күз алдында булырга тиеш.

4. Тавыш бирү бинасында яисә аның каршында ук участок сайлау комиссиясе стенд җиһазлый, анда тутырылган сайлау бюллетененең үрнәге һәм барлык теркәлгән кандидатлар турында мәгълүмати материаллар эленә, аларда үгетләү өндәмәләре булмаска тиеш. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, мәгълүмати материалларда Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) номеры (номерлары) һәм исеме (исемнәре), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, мәгълүмати материалларда

299

тиешле чит илнең исеме күрсәтелергә тиеш. Стендтагы тутырылган сайлау бюллетене үрнәгендә кандидатларның фамилияләре язылырга тиеш түгел.

5. Тавыш бирү бинасында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвеше булырга тиеш, ул ачыкланган саен тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне теркәү өчен файдаланыла.

6. Тавыш бирүне оештыру өчен участок сайлау комиссиясе җаваплы була.

<u>48 статья.</u> Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы

1. Сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы тиешле территория сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 45-25 көн кала) йә шушы сайлау участогының участок сайлау комиссиясеннән (тавыш бирергә 24-1 көн кала) бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, тавыш бирү көнендә кайсы сайлау участогында булса, шунда Татарстан Республикасы чикләрендә тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы (алга таба - бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы) катгый хисап документы була, аның яклану дәрәҗәсен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләү һәм бирү рәвеше, тәртибе, аларны бирү саны һәм реестр рәвеше, шулай ук аларны әзерләүгә карата куелучы таләпләр, тавыш бирү көненә 60 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланалар. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары югарырак сайлау комиссиясеннән түбәнрәк сайлау комиссиясенә сайлау бюллетеньнәрен бирү тәртибендә тапшырылалар.

3. Тиешле сайлау комиссиясе сайлаучының бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын таләп итүенең сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын сайлаучынын шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук сайлаучы дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесе администрациясе тарафыннан да, шик белдерелүче яисә гаепләнүче затларны сак астында тотучы учреждение администрациясе тарафыннан да таныкланырга мөмкин.

4. Администрация башлыгы тарафыннан сайлаучылар турында комиссиягә бирелгән белешмәләр нигезендә территория сайлау комиссиясе сайлаучыга яисә аның вәкиленә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын тапшыра. Территория сайлау комиссиясе бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрын төзи, аларда сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса

300

- өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Тавыш бирергә 25 көн кала территория сайлау комиссиясе участок сайлау комиссиясенә, сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары алган һәм тиешле сайлау участоклары территорияләрендә теркәлгән сайлаучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Шундый өземтә нигезендә участок сайлау комиссиясе сайлаучылар исемлегенә тиешле тамгаларны кертә.

5. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алуы турында сайлаучы яисә аның вәкиле бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына (территория сайлау комиссиясендә) йә сайлаучылар исемлегенә (участок сайлау комиссиясендә) имза салалар, анда аның паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры, алу датасы күрсәтелә. Бу чакта шушы сайлаучы әлеге сайлаулардагы тиешле участок сайлаучылары исемлегеннән төшереп калдырыла һәм участок сайлау комиссиясенең беркетмәсен төзегәндә теркәлгән сайлаучыларның санын санаганда исәпкә алынмый.

6. Әгәр бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгында территория яисә участок сайлау комиссиясенең ике мөһере һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән территория яисә участок сайлау комиссиясенең ике әгъзасы имзасы булса, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы гамәлгә яраклы дип санала, монда мөһернең һәм имзаның берсе аерылма талонда булырга тиеш. Кабат тавыш бирү үткәрелгәндә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы, әгәр анда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән территория яисә участок сайлау комиссиясенең мөһере һәм территория яисә участок сайлау комиссиясе әгъзасының имзасы булса, гамәлгә яраклы дип санала.

7. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәтеп, сайлаучы теләсә кайсы башка сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә тиеш. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткән сайлаучыдан аерылма талон, кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы кире алына. Сайлаучы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы нигезендә сайлау бюллетене алганда сайлаучылар исемлегендә үзе яшәгән урынның адресын күрсәтә.

8. Тавыш бирү көнендә сайлаучы элек сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткән очракта, ул өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә, ә аның бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы кире алына һәм юкка чыгарыла.

9. Тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары

301

юкка чыгарыла, бу хакта тиешле территория яисә участок сайлау комиссиясе акт төзи.

<u>49 статья.</u> Сайлау бюллетене

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны үткәрү өчен һәр сайлаучы сайлау бюллетене ала. Сайлау бюллетененең үрнәге һәм тексты, сайлау бюллетенен әзерләү тәртибе, аларның саны, бюллетеньнәр әзерләүгә булган таләпләр тавыш бирү көненә 25 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Сайлау бюллетененең тексты сайлау бюллетененең бер ягына гына язылырга тиеш. Сайлау бюллетеньнәре Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә басыла, шулай ук теге яисә бу сайлау участогына керүче халык куллана торган телләрдә дә басылырга мөмкин.

2. Сайлау бюллетененә һәр теркәлгән кандидатның алфавит тәртибендә фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, дәүләт хакимияте органында яисә җирле үзидарә органында (булган очракта) кандидат биләгән сайлаулы эш урынының атамасы, төп эш яисә хезмәт (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда шөгыленең төре) урыны, әлеге кандидатның кем тарафыннан күрсәтелүе турында мәгълүмат языла. Кандидатның билгеләнгән тәртиптә җәмәгать берләшмәсенә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча теркәлгән булуы һәм аның статусы сайлау бюллетенендә кандидатның теләге буенча күрсәтелә. Әгәр кандидат турыдан-туры сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан чыгарылса, аларның исеме, шулай ук кандидатның сайлау берләшмәсе, сайлау блогы составына кергән сәяси партиягә яисә башка җәмәгать берләшмәсенә каравы (әгәр анда керсә) күрсәтелә.

3. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем карары булганда, сайлау бюллетенендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, сайлау бюллетенендә тиешле чит илнең исеме күрсәтелергә тиеш.

4. Уң якта һәр кандидат турындагы белешмәләр каршысына буш квадрат урнаштырыла. Кандидатлар исемлеге ахырында «барлык кандидатларга каршы» дигән юл урнаштырыла һәм ул әлеге юлның уң ягындагы буш квадрат каршысында була.

302

5. Һәр сайлау бюллетенендә аны тутыру тәртибе турында аңлатма язылган булырга тиеш.

6. Сайлау бюллетеньнәре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча гына басыла һәм, тавыш бирү көненә 20 көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләренә бирелергә тиеш.

7. Сайлау бюллетеньнәрен дөрес тапшыру өчен сайлау бюллетеньнәрен тапшыруны һәм алуны гамәлгә ашыручы сайлау комиссияләренең рәисләре җаваплы була.

8. Участок сайлау комиссияләре сайлау бюллетеньнәрен акт (ведомость) буенча, сайлауларга дүрт көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләреннән алалар. Участок сайлау комиссиясенә бирелүче сайлау бюллетеньнәренең саны сайлау участогы буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санынннан 0,5 процентган артыграк була алмый. Сайлау бюллетененең өстәге уң як почмагына участок сайлау комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар участок сайлау комиссиясе мөһере белән таныклана. Таныкланмаган сайлау бюллетеньнәре билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр дип таныла һәм тавышларны санаганда алар исәпкә алынмый.

9. Сайлау бюллетеньнәре әзерләнгәннән соң аерым кандидатлар төшеп калган очракта, участок сайлау комиссияләре, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча, төшеп калган кандидатлар турындагы күрсәткечләрне сайлау бюллетеньнәреннән сызып ташлыйлар.

<u>50 статья.</u> Тавыш бирү тәртибе

1. Сайлаулар көнендә тавыш бирү 7 сәгатьтән алып 21 сәгатькә кадәр үткәрелә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән тавыш бирү өчен башка вакыт та билгеләнергә мөмкин.

2. Тавыш бирү вакыты һәм урыны турында территория, участок сайлау комиссияләре, сайлаулар үткәрүгә 20 көннән дә соңга калмыйча, сайлаучыларга хәбәр итәләр. Кирәк булган очракта, территория сайлау комиссиясе, җирле шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, кайбер участокларда тавыш бирү вакытын үзгәртергә дә мөмкин.

3. Сайлаулар көнне иртәнге сәгать 7дә участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирүнең башлануын игълан итә һәм сайлау комиссиясе әгъзаларына, сайлау участогында булган сайлаучыларга һәм күзәтүчеләргә сайлау әрҗәләрен күрсәтә, шуннан соң сайлау әрҗәләре бикләнә һәм аларга мөһер салына.

4. Һәр сайлаучы шәхсән тавыш бирә, башка затлар өчен тавыш бирү рөхсәт ителми. Сайлау бюллетеньнәре сайлау участогының сайлаучылар исемлеге нигезендә, паспорт яисә аны алмаштыручы документ күрсәтелгәч,

сайлау комиссияе тарафыннан бирелә. Исемлеккә тиешле документның сериясе һәм номеры куела. Сайлау бюллетеньнәре алуы хакында сайлаучы шәхсән имза сала.

5. Сайлау бюллетене яшерен тавыш бирү кабинасында яисә бүлмәсендә сайлаучы тарафыннан тутырыла. Сайлау бюллетенен тутырганда, сайлаучыдан гайре, бүтән беркем дә булмаска тиеш. Сайлау бюллетенен мөстәкыйль тутыра алмаган сайлаучы яшерен тавыш бирү кабинасына яисә бүлмәсенә, сайлау комиссиясе әгъзасыннан, күзәтүчедән яисә кандидатның ышанычлы затыннан гайре, теләсә кемне чакыра ала.

6. Сайлау бюллетене алганда мөстәкыйль имза салу мөмкинлеге булмаган очракта сайлаучы бюллетеньне тутырганда башка сайлаучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы, моңа участок сайлау комиссиясе әгъзалары, теркәлгән кандидат, күзәтүчеләр яисә кандидатның, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының ышанычлы затлары, сайлау берләшмәләре, сайлау блокларының вәкаләтле вәкилләре керми. Сайлаучыга ярдәм итүче зат сайлаучылар исемлегенең «сайлау бюллетенен алу турында сайлаучының имзасы» графасында үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, паспортының яисә аны алыштыручы документның сериясен, номерын күрсәтә һәм имза сала.

7. Сайлау бюллетеньнәрендә сайлаучы үзе тавыш биргән кандидат фамилиясенең каршысындагы буш квадратка йә «Барлык кандидатларга каршы» дигән юлдагы квадратка теләсә нинди тамга сала.

8. Тутырылган сайлау бюллетенен сайлаучы тавыш бирү әрҗәсенә сала.

9. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү сайлаучының аңа тавыш бирү бинасыннан читтә бирү мөмкинлеген тудыру турында язма гаризасы яисә телдән мөрәҗәгате (башка затлар аша тапшырылса да) нигезендә үткәрелә. Гариза (мөрәҗәгать) сайлаучы тарафыннан участок сайлау комиссиясе формалашканнан соң теләсә кайсы вакытта, ләкин тавыш бирү вакыты чыкканчыга кадәр кимендә 4 сәгать кала бирелергә мөмкин. Участок сайлау комиссиясе барлык бирелгән гаризаларны (мөрәҗәгатьләрне) махсус реестрда терки. Телдән бирелгән мөрәҗәгатьне реестрда теркәгәндә, аны кабул итеп алу вакыты күрсәтелә һәм телефонаграмманы алган комиссия әгъзасының имзасы куела йә мөрәҗәгатьне тапшырган затның хәбәре язылa. Сайлау комиссиясе әгъзалары сайлаучыга килгәч, мөрәҗәгать язма гариза белән раслана.

10. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы гаризада сайлаучының тавыш бирү бинасына килә алмавының сәбәбе күрсәтелергә тиеш, шулай ук гаризага сайлаучы турында сайлаучылар исемлегендә булган белешмәләр кертелергә тиеш.

11. Участок сайлау комиссиясе җитәрлек санда, ләкин өчтән дә күп түгел, тавыш бирү әрҗәсе булдырырга тиеш, ул югарырак сайлау комиссиясе карары белән билгеләнә.

12. Гаризалар (мөрәҗәгатьләр) буенча чыгучы участок сайлау комиссиясе әгъзалары, имза куеп, сайлау бюллетеньнәре алалар. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия кимендә ике әгъзасы гамәлгә ашыра, алар үзләре белән тавыш бирү өчен участок сайлау комиссиясендә алдан мөһерләнгән (пломба салынган) күчерелмә әрҗә, кирәк кадәр сайлау бюллетеньнәре, әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән реестрның сайлаучы турында, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турында алынган гаризасы (мөрәҗәгате) хакында тиешле белешмәләре булган таныкланган өземтәсен, сайлаучылардан алынган язма гаризаларны, шулай ук язу кирәк-яракларын алырга тиеш.

13. Участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирү бинасындагы тәртипне күзәтеп тора. Аның күрсәтмәләре тавыш бирү бинасындагыларның барысы өчен дә мәҗбүри. Участок сайлау комиссиясе рәисе булмаганда, аны участок сайлау комиссиясе рәисе урынбасары алыштыра, ә рәис урынбасары да булмаганда, участок сайлау комиссиясе секретаре яисә участок сайлау комиссиясенең комиссия вәкаләт биргән берәр әгъзасы алыштыра.

14. Әгәр яшерен тавыш бирү серен бозсалар яисә сайлаучының ихтыяр белдерүенә, сайлау комиссиясенең эшенә кире йогынты ясарга маташсалар, участок сайлау комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарыла. Бу хакта карар участок сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

15. Әгәр сайлаучы сайлау бюллетенен тутырганда хата җибәрдем, дип санаса, ул сайлау комиссиясенең сайлау бюллетенен биргән әгъзасына, бозылганы урынына яңа сайлау бюллетене бирүен сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Сайлау комиссиясе өгъзасы сайлаучыга яңа сайлау бюллетене бирә, бу хакта ул сайлаучылар исемлегендә шушы сайлаучы фамилиясенең уң ягына тиешенчә билгеләп куя. Бозылган сайлау бюллетене юкка чыгарыла, бу турыда акт төзелә.

## 51 статья. Тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясе беркетмәсе

1. Участок сайлау комиссиясе тиешле сайлау участогында тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи.

2. Участок сайлау комиссиясе беркетмәсе бер биттә төзелергә тиеш. Аерым очракларда гына беркетмә бердән күбрәк биттә төзелә ала, болай булганда аның һәр битенә участок сайлау комиссиясенең монда катнашкан тавыш бирү хокукына ия барлык әгъзалары имза салырга тиеш. Участок сайлау комиссиясе беркетмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) нөсхәнең номеры;

б) сайлауларның исеме, тавыш бирү датасы;

305

в) «Беркетмә» сүзе;

г) сайлау участогының номеры күрсәтелеп сайлау комиссиясенең исеме;

д) беркетмә юллары:

1 юл. Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре саны;

3 юл. Тотылган сайлау бюллетеньнәре саны;

4 юл. Тавыш бирү көнендә сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юл. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендә тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

6 юл. Күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

7 юл. Стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

8 юл. Гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре саны;

9 юл. Гамәлгә яраксыз, шул исәптән кайбер юллары буенча гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәренең гомуми саны;

10 юл. Тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләреннән алынган сайлау бюллетеньнәренең саны сайлаучыларның сайлау бюллетеньнәрен алулары турында тамга куелган гаризалары саныннан артып киткәндә, гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау бюллетеньнәре саны;

11 юл. Бер позиция буенча да тамгасы булмаган яисә бердән артыграк позициядә тамгалары булган гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәре саны;

12 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юл. Сайлау участогында тавыш бирү көненә кадәр участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юл. Сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

15 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмыйча юкка чыгарылган таныклыклары саны;

16 юл. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү әлеге Законның 48 статьясындагы 9 пункты нигезендә юкка чыгарылган таныклыклары саны;

е) беркетмәгә кушымта итеп бирелүче шикаятьләр (гаризалар), актлар һәм башка документлар исемлеге;

306

ж) сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретаренең һәм башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары, аларның имзалары;

з) беркетмәгә имза салынган дата һәм вакыт (сәгатьләре һәм минутлары; әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен);

и) сайлау комиссиясенең мөһере (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен).

3. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 17 нче юлына һәм аннан соңгы юлларына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр языла:

теркәлгән кандидатларның алфавит тәртибендә фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алар бер-берсенә тәңгәл килгәндә - теркәлгән кандидатлар турында сайлау бюллетененә кертелгән бүтән белешмәләр;

теркәлгән һәр кандидат өчен сайлаучылар тарафыннан бирелгән тавышлар саны;

сайлаучылар тарафыннан кандидатларның барысына да каршы бирелгән тавышлар саны.

4. Әлеге статьяның 2, 3 пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә цифрлап һәм язмача кертелә.

<u>52 статья.</u> Сайлау участогында тавышларны санау тәртибе

1. Сайлаучылар тавышларын санау хәлиткеч тавыш хокукы булган участок сайлау комиссиясе әгъзалары тарафыннан ачыктан-ачык һәм хәбәрдар башкарыла.

2. Сайлаучылар тавышларын санау тавыш бирү вакыты үткәч үк башлана һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәнгә кадәр өзлексез уздырыла, нәтиҗәләр турында участок сайлау комиссиясенең барлык әгъзаларына, шулай ук күзәтүчеләргә хәбәр ителә.

3. Сайлаучыларның тавышларын санаганда участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәр позициясен билгеләп аны игълан итә, күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә, беркетмәнең зурайтылган рәвешенә кертә, шуннан соң гына киләсе позицияне билгеләүгә күчә.

4. Хәлиткеч тавыш бирү хокукы булган участок сайлау комиссиясе әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затлар катнашында, файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен саныйлар, сул яктагы аскы почмагын кисеп яраксызга чыгаралар (монда бюллетеньдәге теркәлгән кандидатлар турындагы мәгълүматлардан һәм «Барлык кандидатларга каршы» дигән юлдан уң якка урнаштырылган квадратларны зарарлау рөхсәт ителми), аннан соң файдаланылмаган бюллетеньнәр саны игълан ителә, шулай ук тавыш биргәндә сайлаучылар

307

бозган бюллетеньнәр саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 3 нче юлына язып куела.

5. Шуннан соң участок сайлау комиссиясе әгъзалары бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларының санын игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 15 нче юлына язып куялар.

6. Бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең әлеге Законның 48 статьясындагы 8 пункты нигезендә тотылган таныклыклары санала, аларның саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 16 нчы юлына язып куела.

7. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

а) территория һәм участок сайлау комиссияләрендә тавыш бирү өчен бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирелгән сайлаучыларны исәпкә алмыйча, исемлеккә кертелгән сайлаучылар санын;

б) сайлау участогында сайлаучыларга тавыш бирү көнендә бирелгән сайлау бюллетеньнәре санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалар саны буенча билгеләнә);

в) тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга тавыш бирү өчен бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

г) сайлаучыларга участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары санын;

д) сайлау участогында бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар санын.

8. Әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң сайлаучылар исемлегенең һәр битенә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, аннары ул күрсәткечләр сайлаучылар исемлеге буенча тулаем кушып берләштерелә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертелә, участок сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының яки секретаренең имзалары һәм мөһер белән таныклана. Һәр бит һәм исемлек буенча йомгаклар тулаем игълан ителә. Шуннан соң сайлаучылар исемлеге белән әлеге Законның 18 статьясындагы 1, 4 пунктларында күрсәтелгән затлар танышырга хокуклы.

9. Участок сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре түбәндәгеләрне аныклыйлар, игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 1 һәм 2 юлларына кертәләр:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын;

б) участок комиссиясе алган сайлау бюллетеньнәре санын.

10. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

12 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юлга - участок сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юлга - бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча сайлау участогында тавыш биргән сайлаучылар саны.

11. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

4 юлга - тавыш бирү көнендә сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юлга - тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

12. Бу гамәлләрдән соң участок сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре сайлаучылар исемлеген тавышларны санауда катнашучы затлар ала алмаслык итеп саклауны тәэмин итәргә тиешләр. Сайлаучылар исемлеге белән алга таба эш итү бары тик тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары тикшерелгәннән соң гына әлеге статьяның 25 пункты нигезендә башкарылырга мөмкин.

13. Аннары участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирү әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәр буенча сайлаучыларның тавышларын турыдан-туры санауга керешәләр.

14. Сайлаучыларның тавышларын турыдан-туры санаганда участок сайлау комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктта санап үтелгән башка затлар катнаша ала.

15. Сайлаучыларның тавышларын турыдан-туры санау махсус җиһазланган урыннарда үткәрелә, алар сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына да, киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына да керү тәэмин ителерлек җиһазланырга тиеш. Сайлау комиссиясе рәисеннән (рәис урынбасарыннан) һәм сайлау комиссиясе секретареннән гайре, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына тавышларны санаганда язу әсбапларыннан файдалану тыела. Бу вакытта сайлау комиссиясе әгъзаларының гамәлләре тавышларны санаганда шунда булучыларның барысы өчен дә тулы күренүе тәэмин ителергә тиеш.

16. Санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясе рәисе сайлау әрҗәләрендәге мөһерләрнең яисә пломбаларның бөтенлеген тикшерә һәм аларны ача. Сайлау әрҗәләрен ачу түбәндәге чиратта гамәлгә ашырыла: башта - күчерелмә сайлау әрҗәләре, аннары стационар сайлау әрҗәләре ачыла.

309

17. Участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирү өчен күчерелмә һәм стационар әрҗәләрдән алынган сайлау бюллетеньнәрен аерым капларга куеп, теркәлгән кандидатларның һәркайсы өчен бирелгән тавышлар буенча һәм кандидатларга каршы бирелгән тавышлар буенча аралыйлар, бер үк вакытта билгеләнмәгән рәвештәге сайлау бюллетеньнәре һәм гамәлдә булмаган сайлау бюллетеньнәре аерып куела. Бюллетеньнәрне аралаганда участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучының сайлау бюллетенендә булган тамгасын игълан итә һәм бюллетеньнәрне карап тикшерү өчен турыдан-туры санауда катнашучыларның барысына да күрсәтә. Бер үк вакытта ике һәм аннан артык бюллетень эчтәлеген игълан итү рәхсәт ителми.

18. Башта күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре санала. Аларның саны игълан ителә һәм беркетмәнең 6 нчы юлына язып куела һәм ул сайлаучыларның тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалары саныннан артмаска тиеш. Күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге билгеләнгән үрнәктәге бюллетеньнәр санының тавыш бирү бинасыннан читтә сайлау бюллетеньнәре алу турында сайлаучыларның гаризаларындагы тамгалар саныннан артып китүе ачыкланган очракта, әлеге күчерелмә сайлау әрҗәсендәге барлык сайлау бюллетеньнәре участок сайлау комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип танылалар. Бу факт, участок сайлау комиссиясенең тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелеп, аерым актта чагылдырыла, ул акт тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә. Бу очракта гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр саны сайлау йомгаклары турындагы беркетмәнең 10 нчы юлына кертелә.

19. Аннары тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны санала һәм беркетмәнең 7 нче юлына язып куела.

20. Сайлаучыларның тавышларын санаганда, иң элек билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр, ягъни рәсми әзерләнмәгән яисә сайлау комиссиясе тарафыннан таныкланмаган бюллетеньнәр аерып алына. Әлеге бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый. Шулай ук гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дә аерып куела.

21. Сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерүләрен төгәл ачыклап булмый торган сайлау бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дип санала, мондыйларга түбәндәгеләр керә:

бердән артык квадратка билге куелган бюллетеньнәр;

квадратларның берсенә дә билге куелмаган бюллетеньнәр.

22. Сайлау бюллетенен гамәлгә яраксыз дип таныганда шикләнүләр туган очракта, участок сайлау комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә, бу вакытта сайлау бюллетененең арткы ягында гамәлгә яраксызлыгының сәбәпләре күрсәтелә. Бу язу комиссиянең кимендә өч әгъзасы имзасы белән таныклана һәм комиссия мөһере белән раслана.

310

Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр башка сайлау бюллетеньнәреннән аерым җыеп куела.

23. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 9,10,11 нче юлларына кертелә.

24. Участок комиссиясе әгъзалары беркетмәнең 8 нче юлына гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәренең санын язып куялар.

25. Сайлау бюллетеньнәрен санаганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары (4 нче кушымта) тикшерелә. Алар тәңгәл килмәгән очракта, участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юлларын кабат санау турында, шул исәптән сайлау бюллетеньнәрен өстәмә санау турында, карар кабул итә. Кабат санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәрешләр кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең элек тутырылган бланкы тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсенә кушып бирелә.

26. Санаганнан соң теркәлгән кандидатлар буенча сайлау бюллетеньнәре аерым капларга, барлык кандидатларга каршы тавыш бирелгән бюллетеньнәр - аерым, шулай ук гамәлгә яраксыз һәм тотылган сайлау бюллетеньнәре дә аерым капларга тутырыла, һәр капта андагы сайлау бюллетеньнәренең саны, теркәлгән кандидатларның фамилияләре күрсәтелә. Шулай тупланган сайлау бюллетеньнәре капчыкларга яисә аерым тартмаларга салына, аларда сайлау участогының үз номеры (исеме), сайлау бюллетеньнәренең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга пломба салып, мөһер сугыла һәм алар бары тик югарырак сайлау комиссиясе яисә суд карары белән генә ачылырга мөмкин.

27. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә өч нөсхәдә тутырыла һәм аларга участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда имза салынган дата һәм вакыт (сәгате, минуты) куела.

28. Участок сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча участок сайлау комиссиясе, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә имзалар салынгач, кичекмәстән әлеге затларга күчермәсен бирергә яисә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең күчермәсен әзерләргә мөмкинлек бирергә, шулай ук аны таныкларга бурычлы.

29. Участок сайлау комиссиясенең беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерләрен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

30. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

31. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, участок сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар), шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлеп куела. Әлеге документларның таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

311

32. Беркетмәнең беренче нөсхәсе кичекмәстән округ сайлау комиссиясенә җибәрелә һәм участок сайлау комиссиясенә кайтарылмый.

33. Беркетмәнең икенче нөсхәсе, пломба салып мөһерләнгән сайлау документлары белән бергә, сайлау бюллетеньнәрен һәм мөһерне дә кертеп, саклану чан бинада, пломба салып мөһерләнгән килеш, участок сайлау комиссиясенең эше тәмамлаганчы участок сайлау комиссиясе секретаренда саклана һәм сайлау йомгакларын рәсми игълан иткәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча тиешле территория сайлау комиссиясенә тапшырыла.

34. Беркетмәнең өченче нөсхәсе участок сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында гомуми танышу өчен эленеп куела.

35. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салынганнан һәм аны беренче нәсхәсен территория сайлау комиссиясенә җибәргәннән соң беркетмә төзегән участок сайлау комиссиясе анда төгәлсезлек (хата, ялгыш басу яисә күрсәткечләрне кушканда дөрес санамау) тапса, ул үзенең утырышында беркетмәгә аныклаулар кертү турындагы мәсьәләне карарга тиеш. Участок сайлау комиссиясе әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында каралган затларга әлеге утырышның үткәрелүе турында хәбәр итеп, анда әлеге мәсьәләнең каралачагын күрсәтергә тиеш. Кабул ителгән карар турында участок сайлау комиссиясе мәҗбүри рәвештә үзенең киңәш тавыш бирү хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм тавыш бирү йомгаклары турында элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә хәбәр итә. Бу очракта участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Кабат» дигән тамга ясала. Күрсәтелгән беркетмә кичекмәстән территория сайлау комиссиясенә җибәрелә. Тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясенең территория сайлау комиссиясенә элек биргән беркетмәсе кабат язылган беркетмәгә кушыла.

**53 статья.** Территория сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирү йомгакларын билгеләү

1. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләр нигезендә тиешле округ сайлау комиссиясе, аларның дөрес төзелүен алдан тикшергәннән соң, тавыш биргәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча, алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрендәге күрсәткечләрне кушып берләштерүне территория сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үзләре башкаралар.

2. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә хаталар, ярашмаулар ачыкланганда яисә участок сайлау комиссияләреннән кергән беркетмәләрнең төзелүе дөреслегенә шик туганда, территория сайлау комиссиясе сайлаучылар тавышларын кабат санау үздыру турында яисә тиешле сайлау участогында участок сайлау комиссиясе сайлаучыларның тавышларын кабат санауны мөстәкыйль уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау территория

сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында уздырыла. Сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыручы территория сайлау комиссиясе бу хакта участок сайлау комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә, кандидатларга, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктта күрсәтелгән башка затларга хәбәр итә. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча әлеге санауны башкарган участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән билге куела. Беркетмә кичекмәстән территория сайлау комиссиясенә җибәрелә.

3. Территория сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары буенча беркетмә төзи, аңа тиешле сайлау комиссиясе территориядәге участок сайлау комиссияләренең саны турында һәм участок сайлау комиссияләре беркетмәләре саны турында (шуларга нигезләнеп тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзелә) күрсәткечләр, шулай ук участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең әлеге Законның 51 статьясындагы 2, 3 пунктлары берләштерелгән мәгълүматлары кертелә.

4. Территория сайлау комиссиясе беркетмәсе өч нөсхәдә төзелә һәм аларга сайлау комиссиясенең шунда катнашкан хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары аларны төзү датасын һәм вакытын (сәгатен һәм минутын) күрсәтеп имза сала һәм мөһер белән таныклана. Территория сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулысынча яисә аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үз фикерен өстәп куярга хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә түбәндәгеләр беркетелә:

а) тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица, ул тавыш бирү йомгаклары турында кергән барлык участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең тулы күрсәткечләрен эченә ала;

б) территория сайлау комиссияләре, участок сайлау комиссияләре тарафыннан сайлау бюллетеньнәрен алу турында, шулай ук, әлеге бюллетеньнәр санын күрсәтеп, тотылган сайлау бюллетеньнәрен гамәлдән чыгару турында актлар;

в) территория сайлау комиссияләренә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары бирү турында, аларны участок сайлау комиссияләренә тапшыру турында, шулай ук, әлеге таныклыклар санын күрсәтеп, файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тоту турында актлар.

5. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә территория сайлау комиссиясенә кертелгән шикаятьләр (гаризалар) һәм сайлау комиссиясенең алар буенча кабул ителгән карарлары өстәп куела. Шикаятьләрнең (гаризаларның) һәм территория сайлау комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә өстәп куела.

6. Территория сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе һәм җыелма таблица имза салынганнан соң кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә. Җыелма таблицага һәм актларга территория сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалар салына.

7. Участок сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча участок сайлау комиссиясе, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә имзалар салынгач, кичекмәстән әлеге затларга күчермәсен бирергә яисә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең күчермәсен әзерләргә мөмкинлек бирергә, шулай ук аны таныкларга бурычлы.

8. Беркетмәнең икенче нөсхәсе һәм җыелма таблица, участок сайлау комиссияләренең беркетмәләре һәм комиссия мөһере белән бергә, территория сайлау комиссиясе эше тәмамланганчыга кадәр аның секретаренда саклана.

9. Беркетмәнең өченче нөсхәсе һәм җыелма таблица кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә танышу өчен бирелә.

10. Территория сайлау комиссиясе беркетмәсендә хаталар, туры килмәүләр һәм башка төгәлсезлекләр табылганда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тиешле сайлау комиссиясе сайлаучыларының тавышларын Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенең әгъзасы (әгъзалары) катнашында кабат санау турында карар кабул итәргә хокуклы. Территория сайлау комиссиясе «Кабат» тамгасы белән яңа беркетмә һәм яңа җыелма таблица төзи.

## <u>54 статья.</u> Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү

1. Территория сайлау комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре нигезендә алардагы мәгълүматларны берләштерү юлы белән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, тавыш бирүдән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Территория сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләрне Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үзләре берләштерәләр. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тиешле территория сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларның нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, ул Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан имзалана, аңа түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

а) Татарстан Республикасы территориясендәге территория сайлау комиссияләренең саны;

б) тавыш бирү йомгаклары турында территория сайлау комиссияләре беркетмәләренең саны, алар нигезендә тавыш бирү йомгаклары турында әлеге беркетмә төзелә;

в) тавыш бирү йомгаклары турында территория сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге барлык юллар буенча суммар күрсәткечләр.

2. Беркетмәдә түбәндәге карарларның берсе күрсәтелә:

1) теркәлгән кандидатны Татарстан Республикасы Президенты урынына сайланган дип тану. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның яртысыннан артык тавышын җыйган теркәлгән кандидат сайланган дип санала. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның саны тавыш бирү әрҗәләрендә табылган билгеләнгән рәвештәге сайлау бюллетеньнәре саны буенча исәплонә;

2) сайлауларны узмаган дип тану. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны узмаган дип таный:

әгәр сайлауларда тавыш бирү тәмамлану мизгеленә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның яртысыннан кимрәге катнашса (сайлауларда катнашкан сайлаучыларның саны тавыш бирү бинасында һәм тавыш бирү бинасыннан читтә сайлау бюллетеньнәре алган сайлаучылар саны буенча билгеләнә);

әгәр сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган теркәлгән кандидат икенче теркәлгән кандидатка (теркәлгән кандидатларга карата) карата сайлаучыларның барлык кандидатларга каршы бирелгән тавышларыннан кимрәген җыйса;

3) сайлауларны дөрес түгел дип тану. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны түбәндәге очракларда дөрес түгел дип таный:

а) тавышлар бирүне уздырганда яисә тавыш бирүнең йомгакларын билгеләгәндә җибәрелгән хокук бозулар сайлаучыларның ихтыярларын белдерү нәтиҗәләрен дөрес итеп билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта;

б) тавыш бирү йомгаклары дөрес түгел дип танылган сайлау участокларының саны сайлау участокларының гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил иткән очракта;

в) суд карары буенча.

3. Әлеге Законны теркәлгән, әмма тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмаган яисә кабат тавыш бирүдә катнашу өчен җитәрлек санда тавышлар җыймаган кандидатларны сайланырга ярдәм итәрлек итеп бозу йә теркәлгән, әмма кабат тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайланмаган яисә кабат тавыш бирүдә катнашу өчен җитәрлек санда тавышлар җыймаган кандидатлар өчен сайлаучыларны тавыш бирергә этәрү максаты белән яисә этәргеч бирерлек итеп бозу Татарстан Республикасы Президентын сайлауларын дөрес түгел дип тану өчен нигез була алмый.

4. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә барлык территория сайлау комиссияләре беркетмәләренең күрсәткечләрен эченә алган җыелма таблица мәҗбүри төстә кушымта итеп бирелә. Беркетмәгә һәм җыелма таблицага Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең шунда булган барлык хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары имза сала.

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Президентын сайлау нәтиҗәләре турында беркетмәгә имзалар салынгач, танышу һәм күчермә алу өчен беркетмә һәм җыелма таблица күчермәләрен бирергә тиешләр.

5. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турындагы беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәүче хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үз фикерен кушып бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәдә тиешенчә язып куела.

6. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмәне һәм (яисә) җыелма таблицаны имзалаганнан соң Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе аларда төгәлсезлек (шул исәптән ялгыш язу, ялгыш басу йә түбәнге сайлау комиссияләренең беркетмәләрендәге белешмәләрне кушканда хата) ачыкласа, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе үзенең утырышында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага аныклаулар кертү хакындагы мәсьәләне карарга тиеш. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пункты нигезендә утырыш үткәрү турында хәбәр итеп, анда әлеге мәсьәләнең каралачагын күрсәтергә тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе үзе кабул иткән карар турында мәҗбүри рәвештә үзенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларына, элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә.

7. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә һәм (яисә) җыелма таблицаларда хаталар, туры килмәүләр ачыкланганда яисә территория сайлау комиссияләреннән алынган беркетмәләрне һәм (яисә) җыелма таблицаларны төзүнең дөреслегенә шик туганда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тиешле территориядә сайлаучыларның тавышларын кабат санауны үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

8. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне төзүче һәм раслаучы сайлау комиссиясе тарафыннан үткәрелергә, югарырак сайлау комиссиясе йә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тикшерелергә тиеш. Сайлаучыларның тавышларын кабат санауны үткәрүче сайлау комиссиясе бу хакта сайлаучыларның тавышларын кабат санауны үткәргәндә катнашырга хокукы булган тиешле сайлау комиссиясе әгъзаларына, теркәлгән кандидатларга яисә аларның ышанычлы затларына, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затларына хәбәр итә. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча шушы санауны үткәрүче сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга ясала. Тавыш бирү йомгаклары турында элек тәкъдим ителгән беркетмә сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча төзелгән беркетмәгә кушып бирелә.

9. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында рәсми белдерү, беркетмәгә имза салынганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

10. Территория һәм участок сайлау комиссияләренең барлык документлары бер ел саклана, тавыш бирү йомгаклары һәм сайлауларның

316

нәтиҗәләре турындагы беркетмәләр киләсе сайлаулар датасын билгеләгән көннән соң бер ел буе саклана.

55 статья. Кабат тавыш бирү

1. Сайлау бюллетененә икедән артык кандидат кертелеп, аларның берсе дә сайланмаган очракта, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе күбрәк тавыш җыйган ике кандидат буенча Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча кабат тавыш бирүне билгели.

2. Кабат тавыш бирү, әлеге Законның 54 статьясындагы 2 пунктның 1 подпунктында, 4 подпунктның 2 абзацында бәян ителгән таләпләреннән гайре, калган барлык таләпләрен үтәгән килеш, сайлауларның гомуми нәтиҗәләрен билгеләгән көннән башлап ике атнадан да соңга калмыйча уздырыла. Кабат тавыш бирү турындагы белдерү, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән башлап ике көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

3. Әгәр кабат тавыш бирүне уздырганга кадәр Татарстан Республикасы Президенты урынына бер генә кандидат калган булса, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан беренче мәртәбә кабат тавыш бирүне билгеләгәндәге һәм гомуми сайлауларда иң күп тавыш җыйган кандидатлардан соң килүче кандидат Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә кабат тавыш бирүне уздыру өчен икенче кандидат итеп таныла.

4. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат кабат тавыш бирүдә катнашучы сайлаучыларның тавышын бүтән кандидатны хуплап биргән сайлаучылар тавышына караганда күбрәк җыйса, ул сайланган дип санала, әмма кабат тавыш биргәндә кандидатны хуплап тавыш биргән сайлаучыларның тавышлары саны ике кандидатка да каршы тавыш биргән сайлаучыларның тавышларыннан күбрәк булуы шарт.

5. Теркәлгән кандидатлар киткәннән соң бер генә теркәлгән кандидат калган очракта кабат тавыш бирү бер генә кандидатура буенча үткәрелергә мөмкин. Монда тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 50 процент тавышын җыйган теркәлгән кандидат Татарстан Республикасы Президенты урынына сайланган дип санала.

56 статья. Кабат сайлаулар

1. Әгәр Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар узмаган, дөрес түгел дип танылса яисә гомуми сайлауларда йә кабат тавыш биргәндә бер кандидат та Татарстан Республикасы Президенты булып сайланмаса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлауларны билгели.

2. Кандидатлар тәкъдим итү һәм теркәү, кабат сайлауларны уздыруга бәйле башка сайлау гамәлләре әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә уздырыла. Кабат сайлауларны үткәргәндә әлеге Закон белән билгеләнгән сайлау гамәлләренең чорлары Татарстан Республикасының Үзәк сайлау

комиссиясе карары буенча кыскартылырга мөмкин, ләкин өчтән береннән дә артыкка түгел.

3. Кабат сайлаулар беренчел сайлаулар көненнән өч айдан да соңгарак калмыйча уздырыла.

4. Кабат сайлаулар уздырган очракта, гамәлләре (гамәл кылмаулары) гомуми сайлауларны яисә кабат тавыш биргәндәге сайлауларны гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булган кандидатлар яңадан кандидат булып күрсәтелә алмыйлар.

57 статья. Тавыш бирүнең йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгару

1. Һәр сайлау участогы, һәр территория буенча тавыш бирү йомгаклары, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре тиешле сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләр күләмендә сайлаучыларга, теркәлгән кандидатларга, аларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, чит ил (халыкара) күзәтүчеләренә, массакүләм мәгълүмат чараларына аларның таләпләре буенча танышу өчен бирелә.

2. Территория сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында үз беркетмәсендәге мәгълүматларны сайлаулар узганнан соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгара, ә тавыш бирүнең йомгаклары турында участок сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге мәгълүматларны сайлаулар узганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгара.

3. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, сайлаулардан соң унбиш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе беркетмәсе һәм җыелма таблицасы күләмендә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара.

58 статья. Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдалану

1. Сайлаулар уздырганда дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин.

2. Сайлаулар уздырганда, шул исәптән сайлаучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм сайлауларның нәтиҗәләрен ачыклаганда, дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасын тулаем яисә аның аерым программ-техник чараларын гына файдалану тәртибе һәм регламенты турындагы карарны, тавыш бирү көненә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе кабул итә.

4. Дәүләтнең мәгълүмат системасыннан (аның аерым программ-техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясендә һәм округ сайлау комиссияләрендә комиссия әгъзаларыннан төркемнәр төзелә. Сайлау комиссиясенең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелүче теләсә нинди мәгълүмат белән танышырга хокуклы.

5. Тавыш бирүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша алынган күрсәткечләр юридик әһәмияткә ия булмаган якынча мәгълүмат кына була.

## X бүлек. Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе

**59 статья.** Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе

1. Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә сайланган Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан рәсми белдерү ясалганнан соң, утызынчы көннән дә соңга калмыйча, үз вазыйфаларына керешә.

2. Яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты ант иткәнче, Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләр чоры чыкканчы үз вазыйфаларын башкаруны дәвам итә.

## XI бүлек. Гражданнарның сайлау хокукларын бозган өчен җаваплылык

**60 статья.** Гражданнарның сайлау хокукларын бозган өчен җаваплылык

1. Көч куллану, алдау, куркыту юлы белән яисә башка юл белән Татарстан Республикасы гражданының сайлау һәм сайлану, сайлау алды агитациясе алып бару хокукларын ирекле рәвештә гамәлгә ашыруына тоткарлык ясаучы затлар, шулай ук сайлау документларын алмаштыручы, белә торып тавышларны дөрес санамаучы, тавыш бирүнең яшеренлеген бозучы сайлау комиссияләре әгъзалары, дәүләт һәм җәмәгать органнарының урындагы затлары яисә әлеге Законны башка төрле бозучы затлар Законда билгеләнгән җаваплылыкка ия булалар. Җаваплылыкка шулай ук кандидат турында белә торып ялган мәгълүматлар бастырган яисә башка ысул белән тараткан затлар да тартыла.

2. Кандидат тарафыннан әлеге Закон бозылганда ул тиешле территория сайлау комиссиясе тарафыннан кисәтелә, ә кабат бозганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, территория сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча әлеге кандидатны теркәү турындагы карарны юкка чыгарырга мөмкин, бу хакта халыкка игълан ителә.

3. Сайлаулар турында законнарны бозу хакында сайлау комиссияләренә, дәүләт һәм җәмәгать органнарына сайлауларга әзерлек чорында яисә сайлаулардан соң кергән гаризалар биш көн эчендә, ә сайлау алды көнендә яисә сайлаулар көнендә кичекмәстән каралырга тиеш.».

319

**2 статья.** Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазифаларын башкаручы Р.Миңнеханов

Казан шәһәре,
2000 елның 22 сентябре
№350